Дәвалаучы Зөһрә Айнулина: «Яхшы уйда булыгыз!»

«Бүген күпләр рухи яктан үсеш кичерергә тели. Аларга «Бу дөньяга ни өчен килдем?», «Ни өчен яшим?» дигән сораулар тынгылык бирми. Мин шундыйларга «ачылырга», күңелләрен, әйләнә-тирә мохитен чистартырга ярдәм итәм. Минем янга балага уза алмаган хатын-кызлар, озак вакыт дәвамында депрессиядән интеккән, гаилә кора алмаган кешеләр күп килә».

11 БИТ

Аккошлар мәхәббәте... мәңгелек түгел

Ни өчен аккошлар мәхәббәт символы санала, нишләп орнитологлар бала чыгармаучы күкене хөрмәт итә, сыерчыкларның саны нигә азайган? Орнитолог, биология фәннәре докторы Илгизәр Рәхимов кошлар дөньясына кагылышлы сорауларга җавап бирде.

12 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 20.04.2017 | № 42 (5804)   www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

АКТЫ ТАШЫП, АКТЫ ЯРСЫП КАР СУЛАРЫ

Әлки районының Иске Камка авылында яшәүчеләр язгы су басудан инде март аенда хәстәрен күрә башлаган: баздан бәрәңгеләр чыгарылган, йортлар иминиятләштерелгән, техниканы тау башына менгергәннәр, тавык-чебеш, бозаулар өчен өй чормасында урын булдырганнар, документлар һәм кыйммәтле әйберләр полиэтилен пакетларда саклана. Язгы ташу галәмәтләрен алар ишетеп түгел, үзләре кичереп белә.

4 БИТ

Эльвира Мозаффар фотосы

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 69 сум 31 тиен
3 айга 207 сум 93 тиен
6 айга 415 сум 86 тиен

Ташламалы бәядән язылу!

11-21 май, 2017
Абунәче декадасы

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

142 сум 38 тиен 1 айга
427 сум 14 тиен 3 айга
854 сум 28 тиен 6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

САБА

Төбәк авылында яшәүче Шәмселбанат Әскәрова 95 яшьлек юбилеен билгеләп үткән. Ул ятимлек ачысын да, ачлык-ялангачлык михнәтен дә кичергән. Әниләре, алты баланы ятим калдырып, яшьли вафат була. 15 яшьлек Шәмселбанат механизаторлар әзерләү курсларында укый, сигез ел тракторда эшли. Лаеклы ялга чыкканчы, фермада сыерлар сава. Ире Шәяхмәт белән җиде бала тәрбияләп үстергәннәр.

ӘЛКИ

Бертөркем язучылар, Татарстан милли китапханәсе хезмәткәрләре Түбән Әлкидә район китапханәчеләре, укучылар белән очрашты. Язучылар – тансык халык. Шуңадыр да мәктәптә аларны яратып, үз итеп каршы алдылар. Язучылар үз иҗатлары турында сөйләде.

КУКМАРА

Кукмара бистәсе шәһәр статусын алды. Район җитәкчесе Сергей Димитриев сүзләренчә, узган елны Кукмара бистәсен шәһәргә әйләндерү буенча референдум уздырылган. Анда Кукмара халкының 67 проценты катнашкан һәм шуларның 80 проценты әлеге тәкъдимне хуплаган. Сүз уңаеннан, район үзәгендә хәзер 17,5 мең кеше яши.

АКСУБАЙ

Аксубайдан Денис Хан-Баба Россия армиясенең А.Александров исемендәге җыр һәм бию ансамбленең яңа составына кергән. Денис, Әлмәт музыка училищесын тәмамлап, Татарстан дәүләт камера хорында, Казанның опера театрында эшләгән. Александров исемендәге оркестр составының яңартылуын ишеткәч, конкурста катнашып карый һәм 2500 кеше арасыннан беренче турны узып, ансамбль солисты була алган.

АЗНАКАЙ

Эшмәкәрлекне үстерүгә юнәлтелгән «Эшмәкәрләр фабрикасы» республика проекты вәкилләре Азнакайга килеп, киләчәктә бизнес белән шөгыльләнергә теләүче өлкән сыйныф укучылары, үз эшен яңа башлап җибәрүчеләр белән очрашты, аларны бизнес серләренә өйрәтте.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

Апрель ахырында кар ява

Быелгы кыш бигрәк киребеткән булды инде, китәргә һич ашыкмый. Инде яз-сылу килеп тә җитәр дисең, юк, кыш аның саен гайрәтләнә, тунын әйләндереп кага диярсең, апрель ахырында ишелеп кар ява. Татарстанның көньяк-көнчыгыш өлешендә – Лениногорск, Бөгелмә, Азнакай, Баулы районнарында 19 апрель төнендә һәм 20се иртән күпләп кар яуган.

«ВКонтакте» челтәрендә Лениногорскидан шундый фото куелган иде.

Лениногорск районының Урмышлы авылында яшәүче Артур Хәбибуллин «ШК»га сөйләгәнчә, кар бик мул яуган, кар катламы ун сантиметрга кадәр җиткән.

– Язны көткәндә кар явып китү кәефне әз генә җимерде анысы. Әмма шунысы күңелне сөендерә: җир дымны сеңдереп бара, туфракта дым бар. Монысы авыл кешесе өчен бигрәк тә мөһим, – диде ул безгә.

Азнакай районында да кар хәйран төшкән. Беренче Май авылыннан Зәлифә Мостафина сөйләвенчә, аларда кар төне буе яуган.

– Җиргә ун сантиметр калынлыкта кар ятты. Әлегә шул килеш торып тора, эремәде. Көне тыныч үзе, бураны юк. Машина тәгәрмәчләре җәйгегә алыштырылганлыктан, халык барасы җирләренә дә бармый калды. Язгы мәшәкатьләр белән кайнашып, арып беткән идек инде. Көн саен ишегалдын җыештырабыз, мал асларын чистартабыз, абзардагы тиресләрне түгәбез. Менә кар яугач, бераз ял ителде инде, – дип уенын-чынын бергә кушып сөйләде ул.

Татарстанның Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе метеофаразлар бүлеге җитәкчесе Ирина Трущина сүзләренчә, апрель аенда берничә көн кар яву якынча өч елга бер кабатлана. Соңгы тапкыр мондый күренеш 2014 елда күзәтелгән. Ул елны 24-26 апрельдә 6 градус суык булып, юеш кар яуган.

– Алдагы көннәрдә дә һава торышында әллә ни үзгәрешләр булмый. Яңгыр, кар рәвешендәге явым-төшем, урыны белән кыска вакытлы буран булачак. Төнлә һава температурасы урыны белән 6 градуска кадәр суытачак. Көндез 2-3 градус җылылык көтелә, – ди ул.

22-23 апрельдә төнлә – 1 градус салкын, көндез 2-3 градус җылы булачак. Киләсе атнадан исә җылыта башлаячак. Ул атна ахырында синоптиклар һава температурасы +12-13 градус булыр дип фаразлый.

Татарстан Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе шушы берничә көндә температура үзгәреп торганга, юлларда бозлавык хасил булуы мөмкин дип кисәтә. Юл-транспорт һәлакәтләренә юлыкмас өчен, кышкы резиналарын җәйгегә алыштырган машина йөртүчеләргә аеруча сак булырга кирәк, ике транспорт арасындагы ераклыкны саклагыз.

ӘЗ-МӘЗ ТАРИХ

1929 елда Казанда 14,1 градус салкын булган.
1989 елның 14 апрелендә Азнакайда тоташ 12 сәгать кар яуган. Кар катламы 35 см га җиткән.
2002 елның 21 маенда шулай ук 25-30 см калынлыкта кар төшкән.

ХАЛЫК ӘЙТӘ

20 апрельдә яңгыр яуса – балан, суык һәм кояш булса, икмәк, карабодай уңар.
21 апрельдә көн кояшлы икән, җәй җылы килер.
24 апрель көнне сулар агып бетмәсә, яз соңга кала.
25 апрельдә төш вакытында болытлар куерса, ике көн тоташ яңгыр явар.
27 апрельдә катлам-катлам болытлар җәелсә, атна-ун көн эчендә явым-төшем булмас.
30 апрельдә бал кортлары шәмәхә төскә кунса, чия уңышы мулдан булыр.

Шәһәр кәефе



ИЛДАР САФИУЛЛИН,
журналист:

– ТНВ каналында спорт темасын яктыртканлыктан, үзем дә спорт белән шөгыльләнәм. Казанда спорт сарайлары Европа шәһәрләрен көнләштерерлек. Мөмкинлекләр бик зур, ләкин ишегалды спортына игътибар кирәк. Спорт мәйданчыклары һәр ишегалдында булсын иде. Бөтен кешенең дә спорт сарайларында, фитнес клубларда шөгыльләнү мөмкинлеге юк.

ГӨЛҮСӘ МИФТАХОВА,
хезмәткәр:

– Балык Бистәсе районыннан мин, Казанда 2002 елдан яшим. Русиянең башка төбәкләрендә яшәүче туганнарыбыз, кунакка кайткач, Казанның төзеклегенә, матурлыгына сокланып китәләр. Саубуллашканда: «Казанга, Татарстанга барыбер күченеп кайтачакбыз», – диләр. Алар шулай дигәч, Казанда яшәвемә горурлык хисе тагын да арта. Татар телендә чыккан һәр китапны укып барам. Бу җәйдә Баку шәһәренә сәяхәт ниятләп торабыз.

НӘКЫЯ АБДРАХМАНОВА,
пенсионер:

– Лаеш районының элеккеге Мишә Тамагы дигән авылында туып-үстем. 1968 елдан Мөслимдә өч ел район кулланучылар җәмгыятендә эшләп алдым. Шул чордагы хезмәттәшләремне, кунакчыл һәм тырыш мөслимлеләрне сагынып искә төшерәм. Кызыл чөгендер туглап табынга куела торган катыкларының тәмле тәме хәзер дә тел очымда. Казанга 1970 елны күчендем, урамда татар сөйләмен ишетергә зар-интизар булыр идең. Хәзер татар татарча сөйләшергә курыкмый.



АЛИСӘ СИРАЕВА,
хезмәткәр:

– Казанда 2008 елдан, үзем Әгерҗе төбәге баласы. Тауларны яратам. Майлы буяулар белән рәсем ясаганда да тау күренешләрен кулланам. Һәвәскәр генә инде, буяуларны күңел кузгалганда гына тартып чыгарам. Рәсем тәмамланганчы, берничә ай да уза. Ял көннәрендә паркка йөгерергә барам. Казанда парклар һәм скверларны төзекләндерү программасын бик хуплыйм. Агачлар тагын да күбрәк утыртылсын иде. Хыялым – АКШка сәяхәт кылу.

МИДХӘТ МИННУХАНОВ,
пенсионер:

– Кече Елга дигән авыл бар Лаеш төбәгендә, мин әнә шуннан. 1964 елда армиядән кайткач, Казанда янгын күзәтчелеге хезмәтенә эшкә урнаштым. Хәзер яшьләр сүндерә инде янгыннарны, картайдык. Ләкин гомер буе башкарган эш кеше холкына сеңеп кала икән. Халык бакчаларда ут белән сак эш йөртсен, ватык электр җиһазларын файдаланмасын иде. Янгын бик куркыныч нәрсә ул. Бүгенге тормыш-көнкүреш Аллага шөкер.

Өч яшьтән соң да түләргә

Бала тәрбияләү буенча пособиене өч яшькә кадәр озайтырга мөмкиннәр.

Әлеге закон проектын Дәүләт Думасының хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эше комитеты депутаты Сергей Вострецов әзерләгән. Өч яшьтән җиде яшькә кадәр балаларына балалар бакчасында урын булмаган затларга да акча түләнмәгәе. Айлык түләү суммасы бу очракта һәр балага өч мең сум тәшкил итәчәк.

Хәзер бала карау буенча түләүләр беренче ел ярым дәвамында гына бирелә, аның күләме уртача хезмәт хакының якынча 40 процентын тәшкил итә. Әлеге сумма ялга киткәнче булган хезмәт хакы, шулай ук кайсы төбәктә яшәвеңә дә бәйле.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Марат ГАЛИЕВ, Татарстан Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе урынбасары:

– 90нчы еллар башында туганнар хәзер әти-әни булдылар. Ул елларда балалар бик аз туды. Шуңа да алдагы егерме елда туучылар саны кимергә мөмкин. Димәк, демографияне арттыру буенча хәзердән үк чаралар күлланырга кирәк. Бала тәрбияләү буенча пособие бирүне озайту күпмедер дәрәҗәдә моңа тәэсир итәр дип уйлыйм. Әлбәттә, бюджет бик киеренке, тик шулай да яшьләргә шушы юл белән булышлык күрсәтү бүген аеруча мөһим. Бу закон проекты уңышлы булыр кебек.

ТОП – 3

ДӨНЬЯДАГЫ иң куркынычсыз илләр исемлеге билгеле булды. Беренче урында Финляндия тора. Икенче урында – Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, өченчедә – Исландия. Россия әлеге исемлектә 109нчы баскычта. Экспертлар иң куркыныч ил итеп Колумбияне билгеләгән. Шулай ук куркыныч илләр унлыгына Украина да кергән.

ХӘЗЕРГЕ вакытта Россиядә машина йөртүче профессиясе иң таралган һөнәрләрдән санала. Аңа барлык эш белән мәшгуль булучыларның 7 проценты туры килә, дип хәбәр итә «Татар-информ». Икенче урында – сатучы һөнәре. Бу өлкәдә эшләүчеләр машина йөртүчеләрдән аз гына кимрәк.

2017 ЕЛ башыннан Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль күзәтчелек хезмәте (Роскомнадзор) суицидка өндәгән 4 мең «үлем төркеме»нең эшен туктаткан.

8,858 млн сум

Керемнәр турындагы декларациядән күренгәнчә, 2016 елда Россия Президенты Владимир Путин 8,858 млн сум акча эшләгән. Президент декларациядә 1,5 мең кв м җир участогын, 77 һәм 154 кв м лы фатирларын, гараж һәм гараж урынын, ике «Волга»сын, Нива һәм «Скиф» прицепын күрсәткән.

Марат ГАЛИЕВ, Татарстан Дәүләт Советы депутаты:

Хакимият һәм акча – кеше өчен иң авыр сынау.

(Мари Эл башлыгы Леонид Маркеловның ришвәт алуда гаепләнүе уңаеннан «Татар-информ»га биргән шәрехләмәсе)

Татарстанда 26 апрельдә «Хатын-кыз игътибары» «кайнар линия»се эшли башлый. Биредә мәктәпкә 1нче сыйныфка кабул итү, балалар һәм үсмерләрнең җәйге ялын оештыру мәсьәләләре буенча сораулар бирергә мөмкин булачак, дип хәбәр итә Татарстан Дәүләт Советының матбугат хезмәте.

Хатын-кызларга ярдәмгә

Көн дәвамында – иртәнге 8дән 19.00 сәгатькә кадәр – Татарстанда яшәүчеләрнең сорауларына Дәүләт Советы депутатлары, Татарстанның Мәгариф һәм фән, Яшьләр эшләре һәм спорт, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыклары вәкилләре, кеше хокуклары, бала хокуклары буенча аппарат хезмәткәрләре, «Җәй» үзәге, Татарстанның яшь юристлар ассоциациясе, Казан, Чаллы һәм Әлмәт мэрияләре хезмәткәрләре җавап бирәчәк.

Татарстанда беренче тапкыр «Хатын-кыз игътибары» «кайнар линия»сен Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе төбәкнең бала хокуклары буенча вәкиле Гүзәл Удачина белән берлектә оештыра.

«Кайнар линия» телефоннары: **236-00-71, 236-40-17** һәм **236-40-62.**

Эчкечеләрнең саны азайган

Роспотребнадзор 2016 елда алкоголь һәм тәмәке кулланучыларның саны азаюын хәбәр итә. Беренче тапкыр «Алкоголизм» диагнозы куелучыларның саны – 36 процентка, алкоголизм белән чирләүчеләрнең саны 24 процентка кимегән. Тәмәке тартучыларның сафы да кимүгә таба бара. Андыйларның саны 39 процентка ким булып чыккан. 2009 ел белән чагыштырганда, Россия халкы өч тапкырга азрак эчә икән. 2016 елда аракыны бер кеше елына якынча 10 литрдан артыграк эчсә, алты ел элек бу сан 15 литр булган.

Резеда ХӘЕВА, нарколог:

– Татарстанның күп кенә министрлыклары һәм ведомстволары алкоголизмны кисәтү буенча зур эшләр алып бара. Бу дәүләт программасында да каралган. Аның максаты – кешедә үзенең сәламәтлегенә кайгыртучан караш булдыру, актив сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау. Яшьләр дә сәламәт яшәү рәвеше алып баруга һәм физик активлыкка игътибар итә башлады.

ГАҖӘП

Фонтанда – 1,4 миллион евро

Туристлар Римның атаклы Треви фонтанына узган елны 1,4 млн евро акча ыргыткан. Ышанулар буенча, фонтанга аркаң белән басып, уң кулың белән суга акча ыргытсаң, Италия башкаласына кире әйләнеп кайтасың, имеш. Моңа ышанган туристлар арасында шулай акча ыргыту гадәте барлыкка килгән. Җыеп алынган акчаны хәйрия эшенә тотарга ниятлиләр.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстанда «Бабич» дип исемләнгән беренче башкорт тарихи нәфис фильмы экранга чыга. Күпметражлы картина башкорт поэзиясе классигы, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Шаһзадә Бабичка багышланган. Фильмның нигезе итеп 1916-1919 еллардагы тарихи документлар алынган.

* * *

Мари Элда туристлар өчен «Мин монда: Йошкар-Ола» дигән мобиль кушымта эшли башлый. Ул үз эченә республикада урнашкан 200 объектны да ала. Аның бөтен функцияләре офлайн-режимда эшләячәк.

* * *

Чувашиядә медицина хезмәткәрләре өчен «Артык килограммнардан котыл» дигән проект эшли башлаган. Белгечләр медицина хезмәткәрләренә ябыгырга гына булышып калмый, сәламәт туклануга күчәргә, яшәү рәвешен үзгәртергә, зарарлы гадәтләрне ташларга да булыша.

Магнит давыллары

Апрельдә магнит давыллары азрак күзәтелә. Шундый көннәрнең берсе – 20 апрель. Бу көнне уртача чагылыштагы магнит давыллары күзәтеләчәк. Табиблар йөрәк авырулы һәм кан басымы югары күтәрелүче кешеләргә игътибарлырак булырга киңәш итә.

АБАУ

Бертуган... ир белән хатын

Американың Миссисипи штатында яшәүче бер пар, балалары булмаудан зарланып, табибларга мөрәҗәгать иткән. Алар бик күп анализлар тапшырган, шул исәптән ДНК-тест та. Соңгысы ир белән хатынның игезәкләр булуын ачыклаган. Бертуганнарны, әтиәниләре юл һәлакәтендә вафат булгач, икесен ике гаиләгә тәрбиягә биргәннәр. Яшьләр колледжда укыганда танышканнар һәм өйләнешкәннәр, дип яза Лайф.

Акты ташып, акты ярсып кар сулары



Зөлфия Хәлиуллина фотолары

АКТУАЛЬ ТЕМА

Әлки районының Иске Камка авылында яшәүчеләр язгы су басудан инде март аенда хәстәрен күрә башлаган: баздан бәрәңгеләр чыгарылган, йортлар иминиятләштерелгән, техниканы тау башына менгергәннәр, тавык-чебеш, бозаулар өчен өй чормасында урын булдыргannар, документлар һәм кыйммәтле әйберләр полиэтилен пакетларда саклана. Язгы ташу галәмәтләрен алар ишетеп түгел, үзләре кичереп белә.

Эльвира МОЗАФФАР,
Казан – Әлки, Иске Камка

Ел саен Ермак, Кече Чирмешән елгалары ташып, түбәндә урнашкан урамнарга су керә. Узган елларда кинәт җылытып җибәрү сәбәпле, камкалыларга көймәгә күчәргә туры килгән.

Иске Камка авылына кергәнче үк ургылып аккан Ермак елгасы янында туктадык.

– Үзара салым акчасына авылда 430 метр юл салдырган идек. Елгадан чыга торган күперне ел саен су алып киткәнгә, быелтыр көз таш юл ясаттык. Быел су баскач, барлык эшләребез дә бушка булды дип курыккан идек. Шөкер, ташу юл өстеннән берничә көн акты да тынды. Ян-якларындагы туфрак ашалса да, ул нык булып чыкты, – дип сөенә Иске Камка авылы башлыгы Фәргать Әкбәров.

Су басуны авыл халкы марттан бирле көтә. Социаль челтәрләрдән, кинәт җылытып, быел 100 елга бер була торган су басулар булачак икән, дигән хәбәрне укыгач, аеруча курыккан алар.

– Безнең авылда 31 йортка су басу куркынычы яный. Аларда 87 кеше яши, шуларның җидесе – 18 яшькәчә балалар. Халык белән саклык чаралары турында аңгәмәләр үткәрелде. Районның гадәттән тыш хәлләр идарәсеннән белгечләр килеп, аңлату эшләре уздырдылар. Улбу була калса дип, көймәләребез дә әзер, – ди Фәргать абый.

Көймәләрнең кирәге чыккан инде. Безне дә бер урамнан икенчесенә көймәдә чыгардылар.

– Менә шулай ишкәкче булып беттем инде. Елга ташып, юлларны су күмгәч, сөт флягаларын икенче як урамга көймә белән ташыдык. Кешеләрне эшкә, балаларны мәктәпкә озатабыз. Гадәттә, урамнарга кергән су атна буе тора. Ул чакта кешеләр өйләреннән чыга алмый. Һәрберсендә телефон бар. Кирәкле продуктларны, даруларны көймә белән өйләргә таратып йөрибез. Шөкер, быел язгы ташу алай ук зыянлы булмады, – ди Радик абый.

Иң көчле су басуларны 1999, 2010 елларда булды дип хәтерли авыл халкы. Хәер, елга ярындагы кайбер йортларга быелтыр да су кергән. Роберт Вәлиуллинның, су кереп, җылылык казаны эштән чыккан.

– Йорт иминиятләштерелгән анысы. Су өйгә керсә, аның таушалганын еллар узгач кына сизә башлыйсың. Күңелле нәрсә түгел, әлбәттә. Тик нишләтәсең, аның каравы, бакчаларга су кергәч, дым яхшы саклана, бәрәңгеләр уңа, – дип елмая үзе.

Шунысына игътибар иттек, Иске Камка авылында берәү дә зарланырга яратмый. Әллә язгы ташуларга ияләшкәннәр, әллә үзләре шундый позитив халык, һәр нәрсәнең уңай ягын күрергә тырышалар.

– Су баскач, болыннар яшәреп китә. Елгаларга балыклар тула. Хәтта су баскан йортларда сарайларда балыкларны кул белән җыеп алырлык була. Яшелчәләр өчен дә файдалы язгы дым, – ди үзләре.

Елгаларның ярларыннан 6,5 метрга җәелүе Иске Камка авылы өчен критик күрсәткеч булып санала. Быел су 5 метр 50 сантиметрга күтәрелгән. Шөкер, ташу йортларга үк керми калган. Дымның җиргә сеңеп баруы, яңгырларның кар катламын акрынлап эретүе, кинәт җылытып җибәрмәү, вакыт-вакыт суык көннәр саклану – болар барысы да язгы ташуга ярсырга, елгаларга ярларыннан ташарга ирек бирмәгән. Шулай да табигатькә ышанып булмый. Кама елгасы ярларыннан күтәрелсә, авылдагы сулыкларның ташу куркынычы бар әле.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан идарәсе хәбәр итүенчә, республика территориясендәге 42 районга су басу куркынычы яный. Бу зоналарда яшәүчеләрне эвакуацияләү маршрутлары инде күптәннән әзер. Язгы ташу чорында, вакытлыча урнаштыру өчен, 32 меңнән артык кешене сыйдыра алырлык 149 пункт билгеләнгән. Язгы ташуларны стационар гидрологик постта кизү торучылар контрольдә тота.

Равия Кәримуллина, Кукмара районы башлыгы урынбасары:

– Былтыр беренче тапкыр Нурминкә елгасында боз тыгылып, Кукмараның биш йортына су кергән иде. Нократ елгасы буенда урнашкан Любян авылында да 40лап йорт су астында калды. Бу авылдагы дамбаның таушалуына да бәйле. Шул хәлләрдән соң район башлыгы Татарстан Президентына мөрәҗәгать итте. Хәзер дамбаны ныгыту буенча документлар Мәскәүдә карала. Бу хәлләрдән соң, язгы ташулар вакытында халык аеруча саклык чаралары күрә. Районның гадәттән тыш хәлләр комиссиясе даими аңлату эшләре алып бара. Әлеге мәсьәләне район башлыгы үзе дә контрольдә тота. Әлегә Кукмарада су басу куркынычы янамый. Нократ елгасы билгеләнгән тамгадан 750 метрга күтәрелсә, куркыныч булып санала. Былтыр бу күрсәткеч 810 метрга җиткән иде. Быел су бары 400 метрга гына арткан. Шулай да алдан берни әйтеп булмый. Былтыр Лубян авылын су 27 апрельдә басты. 10 майга кадәр кайбер өйләр диңгез өстендә йөзгән кебек торды. Ни хикмәт, күпләрнең өйләрен ташлап китәсе килми. Көймәдә йөриләр. Бюджеттан ел саен су басканда ярдәм күрсәтү өчен акча карала, халыкны эвакуацияләү өчен йортлар һәрчак әзер.

Камил Шәкүров, Яшел Үзән районының Норлат авылы җирле үзидарәсендә әйдәп баручы белгеч:

– Безнең Норлат авылында буа бар. Су басмасын өчен, андагы су күләмен һәрчак контрольдә тотабыз. Быел буаны төзекләндерергә, ныгытырга җыенабыз. Норлат җирлегенә кергән Прибой авылында язгы ташулар вакытында ел саен юллар проблемасы килеп чыга. Прибойда яшәүче 25 кеше ике атна тирәсе авылдан чыга алмый. Алар моңа алдан әзерләнә. Азык запасы әзерли. Табиб чакырырга туры килсә, берәр нәрсә кирәк булса, телефон аша элемтәгә чыгалар. Андый вакытта ничек тә авылга керү җаен эзлибез. Кызганыч, Әрә елгасы ярыннан ташып акканда, бу авылга берничек тә барып булмый. Юлсызлык проблемасын җыелышларда да күтәрәбез. Бу хакта район җитәкчелеге дә белә. Киләчәктә анда юллар төзелер, проблема уңай хәл ителер дип ышанасы килә. Быел Әрә елгасы артык күтәрелмәде. Прибойдагы пычрак юллар да өч көннән кибәр дип уйлыйбыз.

Айдар Хәлиуллин, Азнакай районы советы аппараты җитәкчесе:

– Быел Азнакайда су баскан авыллар юк. Дөрес, Тымытык авылында Яшьләр урамындагы бер түбә астында урнашкан ике фатирда яшәүчеләр басудан төшкән кар суларыннан азрак зыян күрде. Ташу аларның гаражлары аша узган, базга төшкән. Шөкер, өйләргә кермәгән. Ык елгасы буенда урнашкан унлап авылга аеруча сак булырга туры килә. Гадәттән тыш хәлләр комиссиясе дә ул авылларда кисәтү эшләре алып бара. Иң көчле су басу 2012 елда булган иде. Ул чакта да су йортларга кермәде анысы, ишегалларына кадәр генә җәелде. Халык бу күренешне сокланып күзәткән иде. Быел Ык әллә ни күтәрелмәде. Язгы ташуларны тыныч уздырырбыз дип ышанам.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

ӘЛЕГӘ СОҢ ТҮГЕЛ

Редакциягә Казанның Полевая урамы, 36нчы йортта яшәүчеләр борчылып шалтыратты. «Йортыбызга – 58 ел. Яшәр өчен шартлар тудырылмаган. Капиталь ремонт та ясамыйлар, безне башка торакка да күчермиләр. Әле менә канализация торбалары шартлап, йортыбызны су басты, ишегалдында йөрерлек түгел. Ярдәм итегез», – диде укучыбыз, җан авазы белән.

Эльвира МОЗАФФАР

Ике катлы таш йорт 1959 елда салынган. Канализация торбалары тыгылганга, подъезд алларын пычрак су баскан, өстәвенә яман ис килә. Барлык шакшы калдыкларның шулай җир өстендә йөзеп йөргән күргәч, күңелсез булып китә. Биредә яшәүчеләр моңа ияләнгән бугай.

– Беренче генә тапкыр түгел инде мондый хәл. Мин монда бишенче ел яшим, «аксакал»лар, торбалар гел тыгыла, дип зарлана. Су агып китсен өчен, канализация люкларын азрак ачып куярга туры килде. Әмма су белән бергә бу чокырларга туфрак та кушылып ага. Нәтиҗәдә, люклар тыгылып, канализация суы урамга бәреп чыкты. Хәзер бәдрәфләрдән шакшы турыдан-туры урамга ага, – дип борчыла дүртенче фатирда яшәүче Рәшидә Ганиева.

Дөрес, «ШК» журналистлары килеп киткәннән соң, икенче көнне үк йорт алдындагы суны суыртканнар, эшчеләр канализация торбаларын рәтләгәннәр иде. Әмма су бетсә дә, яшәүчеләрнең проблемалары калган.

– Безгә 2012 елдан бирле, яңа йортларга күчәсез, дип вәгъдә итәләр. Документлар да җыйдырдылар. Тик берминди үзгәреш күренми, – ди яшәүчеләр.

Рәшидә апа әйтүенчә, йортка капиталь ремонт ясамыйлар. Түбәгә 1959 елдан бирле кеше кулы тигәне юк. Подъезд алларында юллар начар, гел су басып торганга, сазлык хасил була, пычрак. Кайвакыт ул су подъезд эченә, хәтта беренче катта яшәүчеләрнең фатирларына кадәр керә. Балаларга да ишегалдында уйнарга шартлар тудырылмаган.

– Күршебездә салынган йорт каршында заманча уен мәйданчыгы ясап куйдылар. Безнең балалар кызыгып шунда барганнар иде – куып җибәргәннәр. Янәсе, үзегезнең ишегалдында уйнагыз. Безнең балалар башкалардан кимме? Безне кайчан да булса яңа торакларга күчерерләрме икән? – ди әңгәмәдәшебез.

Йортта – 16 фатир. Аларга чынлап та берничә мәртәбә барлык документларны җыеп, идарәче компаниягә тапшырырга кушканнар. Тик әллә оешып бетә алмыйлар, әллә кайберәүләр бу мәсьәләгә битараф, һаман тиешле кәгазьләр тупланып бетмәгән.

Йортка хезмәт күрсәтә торган «Заречье» идарәче компаниясендә баш инженер Петр Мартынов аңлатуынча, Полевая урамындагы 36нчы йорт авария хәлендә дип табылмаган. Ул тузган торак дип санала.

– Кызганыч, «Тузган торак» дәүләт программасы инде тәмамланган. (2014 елдан «Авария хәлендәге тораклардан күчерү» программасы гамәлдә. – **Авт.**) 36нчы йорт янында урнашкан шундый ук 30нчы йортта яшәүчеләр 2014 елда документлар туплап, торакларын авария хәлендә дип танытуга ирештеләр. Аларны икенче елга яңа торакларга күчерү ниятләнелә. Дөрес, 36нчы йорттагыларга да соң түгел әле. Моның өчен идарәче компаниягә килеп, консультация алырга була. Документларны туплап, район хакимиятенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Барысы да яшәүчеләрнең бердәмлегеннән тора. Бер генә кеше булса да йорттан күченергә теләмәсә, эшне дәвам итеп булмый, – диде Петр Мартынов. – Капиталь ремонтка килгәндә, бүген, иртәгә авария хәлендә дип танылырга торган йортка ремонт ясаудан мәгънә юк. Шуңа да тәзекләндерү эшләренә тотынмыйбыз. Йортта берәр кимчелек булса, мөмкин булганча, ярдәм итәргә тырышабыз.

Шәһри КАЗАН тыңлый

Тәкъдим, фикерләрегезне редакциябезгә **8 (843) 562-50-12, 562-50-03** номерлары аша юллый аласыз.

СОРАУ-ҖАВАП

Сорауларга Россия Пенсия фонды Татарстан бүлегенең Вахитов бүлекчәсе хезмәткәрләре җавап бирә.

Мин фрилансер булып эшлим. Сайтлар ясыйм. Эшем ошый, акчасы да әйбәт, беркемгә буйсынмыйсың, үз-үзеңә хуҗа, ирекле график. Тик клиентлар белән килешүләр төземичә генә эшлим, киләчәктә пенсиясез калуым бар дип борчылам. Бу очракта нишләргә?

Альберт,
Казан.

Фрилансер дигән төшенчә Россия законнар җыелмасында бөтенләй юк. Сезнең кебек хезмәт килешүе төземичә эшләүчеләр бик күп. Бу – алар акчаны яхшы эшләсә дә, хезмәт хакыннан социаль фондларга кертемнәр түләми дигән сүз. Мәҗбүри пенсия иминиятенә акчалар күчерелми икән, димәк, сез киләчәктә иминият пенсиясеннән мәхрүм каласыз. Мондый очракта эшләгән стажны, булачак пенсияне югалтмас өчен, хезмәткәрләрнең үзләренә Пенсия фондына иминият кертемнәрен күчереп бару сорала. Моның өчен теркәлү урыны буенча пенсия бүлекчәсенә барып, ирекле иминиятләштерүче булырга теләвегез турында гариза язарга кирәк. Үзегез белән паспорт һәм шәхси лицевой счетның иминият номеры (СНИЛС) да кирәк булачак. Еллык кертемне берьюлы да, өлешләп тә түләргә мөмкин. Пенсия баллары әлеге кертемнәрнең суммасыннан чыгып исәпләнә. Әгәр дә картлык буенча пенсиягә чыгу өчен стажыгыз, баллыгыз җитмәсә, социаль пенсия билгеләнә. Дөрес, аны картлык буенча пенсия яше җитсә дә, бары биш елдан соң гына алырга була. Ягъни ир-атларга ул – 65, хатын-кызларга бары 60 яшьтән соң гына бирелә.

Мин – эшләүче пенсионер. Февральдә, апрельдә индексация булса да, пенсиям бер тиенгә дә артмады. Эшләүче пенсионерларның акчалары бөтенләй артмыймыни?

Мөршидә МИНКИНА,
Казан.

1 апрельдән социаль пенсияләр индексацияләнде, шулай ук кайбер категория кешеләрнең картлык буенча ала торган пенсияләре дә артты. Былтырдан гамәлгә кергән кагыйдәләр нигезендә, индексация бары эшләмәүче пенсионерларга гына кагылды. Шулай да быел эшләүче пенсионерларның да акчалары артачак. Былтыр эшләгән пенсионерларга быелның августыннан иминият пенсияләрен кабаттан исәпләячәкләр. Бу узган ел өчен тупланган пенсия балларына нигезләнеп башкарылачак. Һәр кешенең пенсиясе төрлечә артачак. Пенсиягә өстәлә торган акчаның иң күбе өч пенсия баллы суммасыннан артмаска тиеш. Бер пенсия баллы бүген 78 сум 58 тиен тора.

Әле яңа гына улым туды. Хәзер баланың беренче документларын рәсмиләштереп йөрибез. Туу турында таныклык алдык, ә менә яңа туган сабыйга шәхси лицевой счетның иминият номерын (СНИЛС) рәсмиләштерү нигә кирәк?

Илгиз ХӘЙРУЛЛИН,
Казан.

Шәхси лицевой счетның иминият номеры, кыскартып әйткәндә, халык телендә СНИЛС дип аталган документ мәҗбүри медицина иминияте полисы, балага төрле пособиеләр рәсмиләштергәндә кирәк. Бүген бу гади генә «яшел карточка» – балага тугач ук кирәкле документларның берсе. СНИЛС медицина хезмәтләреннән файдаланганда, ташламалы препаратлар алганда, шифаханәгә юллама рәсмиләштергәндә дә таләп ителә. Ускәч, бала каникул вакытларында акча эшләргә уйласа да, эш урыныннан бу документны сорыйлар.

Мартта миңа 60 яшь тулды. Мин – хәрби пенсионер. Әмма Пенсия фондында гражданнар пенсиясен бирмәскә булдылар. Бу законлымы?

Мөнир ӘХӘТОВ,
Казан.

Хәрбиләргә түләнә торган картлык буенча пенсиягә фиксацияләнгән түләү – 4805,11 сум кертелми. Әгәр хәрби пенсиягә чыккач та, гражданнар учреждениесендә эшләвен дәвам итә икән, аның иминият пенсиясе ел саен үзгәреп бара дигән сүз. Ә картлык буенча бирелә торган гражданнар пенсиясен барлык хәрби пенсионерлар да ала алмый.

Ул түбәндәге шартлар исәпкә алынганда гына бирелә:

– ир-атлар өчен – 60 яшь, хатын-кызлар өчен 55 яшь тулу мәҗбүри;

– гражданнар оешмасында иминият стажы җитәрлек булырга тиеш (2017 елда пенсиягә чыгучылар өчен ул 8 елны тәшкил итә);

– пенсия баллары җитәрлек булу мөһим (2017 елда ул 11,4 баллдан да ким булмаска тиеш). Сезнең очракта бу таләпләр исәпкә алынмаган булып чыга. Сезгә кабат, теркәлү урыны буенча Пенсия фондына барып, барысын да ачыкларга, тикшертергә кирәк.

САКЛАНГАННЫ САКЛАРМЫН

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

vk.com

«Армиядән калма! Алмасалар, талашып булса да кит». ТАССРның халык артисты, «Әлдермештән Әлмәндәр»дә Евстигней картны уйнаган Һидаят Солтановның әтисе бу сүзләрне колагына киртләп куйган. Туфан Миңнуллин көндәлекләрендә шулай дип язып калдырган.

30нчы еллар ахыры бу, Һидаять – хәрби заводта, анда эшләүчеләрне бронь белән калдыра торган булганнар. Һидаятне дә калдырганнар. Менә шунда әтисе әйткән: «Бел дә тор, тиздән сугыш башланачак, ул сугыштан синең яшьтәгеләр калмаячак. Ни әйткәнемне беләм мин, герман сугышында катнашкан кеше. Монысы тагын да хәтәррәк булачак. Сугышка сукыр килеш барып керергә ярамый. Солдат хезмәтен узып кайтсаң, сакланырга өйрәнеп кайтасың».

«Әти сүзен тыңладым, һәм чыннан да, сугыш вакытында армиядә булуның бик зур файдасы тиде. Сукыр килеш сугышка килеп кергән күпме егетләребез әрәм булды. Сугыш бит ул кинодагыча «Ура!» кычкырып йөгерү түгел. Аның төп сере – үзең үлмичә, дошманны юк итү», – дип сөйләгән Һидаят абый язучыга.

Аллага шөкер, мин фәкыйрегезгә сугышларга эләгергә язмады, тик һәр чорның үз бәласе дигәндәй, безнең яшүсмерлек-яшьлек чорларына гопниклар, группировщиклар «чәчәк аткан» вакыт туры килде. Хәзер кайберәүләр ул чордан ниндидер романтика эзләп тапмакчы була, шул вакыттагы банда исемнәре белән футболкалар чыгара башлаганнар, ләкин чынлыкта исә ул сугышка тиң бер куркыныч күренеш иде. Без, авылда үскән малайлар, бу әйберләрдән азмы-күпме сакланган идек. Ә менә шәһәрдә үскән бер дустым күптән түгел генә исенә төшереп торды, 1988 елда ул укыган мәктәптә 11 кешегә (балага!) җинаять эше кузгатылган булган. «Безнең йортта яшәгән 10нчы сыйныфта укучы малайны үз фатирында асып куйдылар, кем үтергәнен таба алмадылар. Икенче бер күрше малай, ә аңа 14 кенә яшь иде, тагын өч «подельнигы» белән бергә кеше үтергән өчен төрмәгә утырды. Минем классташымның эченә пычак белән кереп чыктылар», – дип санап чыкты дустым. Минем исә күрше авылдагы хәлләр искә төште. Бер төндә Иске Мәҗында җиде кешене атып үтергәннәр иде...

Шуларны да уйлаптыр инде, күрәсең, әнинең мине Казанга укырга бер дә җибәрәсе килмәгән иде, тик мин уҗәтләнеп барыбер университетка барып кердем. (Анысы үзе бик кызыклы тарих, бер язылыр әле.) Әллә тулай торакта тормаганга (мин чыбык очы туган бер әбинең фатирында бүлмә «снимать» итеп тордым Казанда укыганда), әллә кирәкле-кирәксез урыннарда маҗара эзләп йөрмичә өйдә баш күтәрми укып һәм язып ятканга, «мотальщик»-мазарлар белән очрашырга туры килмәде миңа, Аллага шөкер. Тик шулай да берсендә бик четерекле хәлдә калган идем...

1991 елда кышын Казаннан автобуска утырып Минзәләгә кайтып киттем. Бүгенгедәй исемдә, аклы-зәңгәрле «ЛАЗ» автобусы иде ул, үкерә-үкерә, көчәнә-көчәнә, шалтыр-шолтыр, дөбер-шатыр кайта бу, мин сиңа әйтим! «Кыр уртасында ватылмаса гына ярар иде», – дип уйлап та бетермәдем, шартлап сүнде бу драндулет. Өч сәгатьләп «җан» кертергә тырышты автобусына шофер. Аңа пассажирлар арасыннан ике-өч ир-ат булышты. Каттык, өшедек! Ниһаять, кабынып китте автобус!

Минзәләгә кичке алтыларда кайтырга тиеш идек, тугызларда гына кайтып җиттек. Ул вакытларда автобуслар кешеләрне шәһәр читендәге автовокзалда төшерә торган иде. Соңга калгач, шофер безне жәлләп, Минзәләнең үзәк мәйданына кадәр – почтамт янына китереп куйды.

Белмим, хәзер дә шулай микән, ул чакта Минзәлә өчкә бүленгән иде: Поселок (анда күбрәк нефтьче гаиләләре яши иде), Конка (элегрәк бу урында бик зур ат базары булган, шуннан калган исем) һәм Колхозка (иске шәһәр). Почтамт Колхозкага керә, миңа Поселокта яшәүче туганнарга барырга кирәк. Шактый гына суык төн иде ул, юлда да өшеп беттек, шуңа мин, тиз-тиз атлап, караңгы урамга кереп киттем. Йөз метрлап та узмаганмындыр, каршыга җиде-сигез егет килә. Кыяфәтләреннән сизелеп тора: хәзер бәйләнәчәкләр.

Безнең ара торган саен якынлаша. Борылып кирегә йөгерсәң, үзеңә генә начар эшлисең, алар куып, барыбер берәрсе куып тотачак. Ярар, ни булса, шул була инде дип, атлавымны дәвам итәм, нык басарга тырышам.

Очраштык. Тәмәке сорадылар. Тартмыйм, дим. «Син каян соң, нишләп без сине белмибез?» – ди берсе. Авылдан дисәң, кыйнап, барлы-юклы акчаларны да талап ала инде болар. Колхозкадан яки Конкадан дияр идең, мин анда беркемне дә белмим, ә болар, киресенчә, бөтен кешене дә белә, ялган шундук ачылачак. Поселоктан диярга ярамый, чөнки ул вакытта Колхозка малайлары белән поселокныкылар асфальт бүлешеп сугыша иде. Чаллыдан килдем, дисәң дә эчеңә пычак белән кереп чыгулары бар, чөнки ул чакларда Минзәлә бандитлары чаллыныкылар белән гел сугышып кына торалар иде.

Бу уйлар бит баштан секундның йөздән бер өлешендә узды! «Син каян соң, нишләп без сине белмибез?» – дигән сорау яңгырау белән, мин шундук тыныч кына: «Казаннан», – дип җавап бирдем. Алдашмадым бит әле өстәвенә, дөресен әйттем.

– Нишләп әле без сиңа ышанырга тиеш? – дип сорады берсе. (Сөйләшү урыс телендә барды инде, әлбәттә.)

– Әнә бит Казан автобусы тора, яңа гына шуннан төштем, – дим, почтамт ягына ишарәләп.

– Кая барасың?

– Эш буенча, – дим. Чөнки Поселокка дисәң, сүнеп барган учакка утын ташлаган кебек була.

– Нинди эш?

– Миңа ярамый әйтергә, сорамагыз, – дим.

Үземнең уң кул кесәдә, юри чыгармыйм. Эт белсен, ул кесәдә ни булмас?! Тавыш та бик көр генә чыга минем, курку әллә кая китеп югалды. «Бу Казан дураклары белән бәйләнгәнче», – дип уйладылар микән инде, «пока», – дип китеп бардылар болар.

Шулай шул, тикмәгә генә әйтмәгәннәр инде, беләге булган берне егар, белеме булган (башы эшләгән) меңне егар дип.

Милли фронтта кечкенә генә булса да бер җиңү яуларга да булышкан иде ул баш эшләү миңа. 2011 елның апрель башлары. Чаллы хакиме матбугат конференциясе җыйды. Ирешелгән уңышлар турында сәгатьтән артык сөйләде. Фәлән кадәр «КАМАЗ» автомобиле конвейердан чыккан, төгән кадәр квадрат метр торак төзелгән, фәлән миллиард сумлык товар сатылган, төгән кадәр пассажир йөртелгән һ.б.

Тукайның 125 еллык юбилее елы иде ул, шул турыда ни дә булса әйтер микән дип көтәм мин. Ниһаять иң ахырда бер җөмлә яңгырады, анысы да урысча: «Проведен конкурс детских рисунков, посвященный 125 летию великого татарского поэта Габдуллы Тукая».

Журналистларның сорауларына чират җитте. Һәрвакыттагыча ЖКХ, эшләми торган лифтлар, чистартылмый торган тротуарлар, җимерек юллар турында китте сүз. Дүртенчеме, бишенчеме булып, миңа да сүз бирделәр.

«Сүз дә юк, шәһәрдә чыннан да зур икътисади һәм социаль проектлар тормышка ашырыла, ирешелгән уңышлар да күп, сөенерлек урын бар, – дип башладым мин. – Тик килешәсездер, балалар арасында рәсем бәйгесе ел саен үткәрелә, бөек Тукайның 125 еллык юбилеен моның белән генә чикләү, минемчә, һич тә дөрес түгел. Үзегез дә күреп тордыгыз, әле ике атна элек кенә Казанга килгәч, Төркиянең премьер-министры Рәҗәп Эрдоган Дәүләт Советы трибунасыннан татар телендә Тукай шигырен укып күрсәтте. Чаллы дөньяга «КАМАЗ»лары аркасында танылса, татар халкы дөньяга Тукае булганга билгеле. Алдан әйткәнемчә, Чаллыда бик күп зур проектлар тормышка ашырыла. «КАМАЗ» төзелгән еллардан ул шулай традициягә кереп калган, Чаллы дигәч, беренче чиратта масштаблы эшләр күзалдына килә. Әгәр дә инде ярты миллионнан артык кеше яшәгән Татарстанның икенче шәһәрендә, Чулман аръягының башкаласында татар театры өчен бина төзү безнең көчебездән килми икән, ичмасам, Тукайның 125 еллыгына булса да без аңа һәйкәл куя алабызмы?»

Спикер бер мизгелгә югалып калган сыман тоелды миңа, ул як-ягына караштыргалап алды, тик шулай да җавапны бик тиз һәм бик кыска итеп бирде: «Алабыз!»

Матбугат конференциясе беткәч, лифт янында бер таныш чиновник белән икәү генә калдык ничектер. «Ну, Равил, сорауны куя да беләсең инде үзең, – ди бу, борын астыннан гына мыгырданып, үзе никтер миңа түгел, идәнгә карап тора. – Тагын ни дип җавап бирмәк кирәк инде мондый сорауга?! «Юк», – дисәң, портфельне тапшырып, кәнәфиеңне бушатаса гына кала».

...Һидаят абыйның сөйләгән сүзләрендә (Туфан абыйның язганнарында) сакланудан бигрәк, әзерлекле булу турында сүз бара, минемчә. Ә аларны сагынып әллә нинди уйларга батуым бер дә гаҗәп түгел. Чөнки Һидаят абый мине беренче мәртәбә Камал театрының сәхнә артына алып кергән кеше, ә Туфан абый драматургиянең кайбер серләрен ачып бирде...

И адәми аппетит!

САКАЛЛЫ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

Элегрәк район гәзитләрендә, хәтта республиканыкыларда да хезмәт алдынгылары, авыл хуҗалыгы эшчәннәре, игенчеләр, малчылар турында язалар иде. Һәм андый язмалар беркадәр калыпланганрак була, ә инде жанрның иң югары ноктасы – ниндидер малчының сарык бәрәне яки бозау кочаклап төшкән фотосы була торган иде. Хайваннарның баласы да бала бит инде. Матур алар шундый. Соклангыч. Аларны чынлап та кочаклыйсы, иркәлисе килә. Бүген андый язмалар юк инде, авыл хуҗалыгы үзе дә юкка чыгып бара бугай.

Кайчагында шундый язмаларны сагынам мин. Алар тансык булып тоела. Гәзит өчен үзем эшләрмен әле дип уйлыйм да – онытам. Кайбер төбәкләрдә, тыйнак кына итеп: «Бездә малчылык юк шул инде», – диләр. Кайсысында – сарык, кайсысында – бозау, кайсысында айнык малчы табып булмый. Соңыннан онытыла.

Ниндидер савымчы яки бозау караучы турындагы язманы укучы кабул итәр иде микән? Белмим, әйтә алмыйм.

Миңа калса, бик исе китмәс идедер кебек. Чөнки без инде гади хезмәт кешесен мактаудан бөтенләй читләштек. Кешеләргә файда китерә торган гамәлләр, әгәр җитди төшем бирми икән, бик сәер булып тоела. Без «файда» һәм «төшем» дигән сүзләрнең мәгънәсен бер иттек.

Аннан соң, без тозлы, борычлы, канлы күренешләргә күнектек. Без телевидениедән үтерешләр белән шыплап тутырылган яңалыклар карыйбыз. Анда «коточкыч» жанрына караган фильмнардан да хәтәррәк хәлләрне күрсәтәләр. Мәетләр, кан, үлем. Без шуларны карый-карый, якыннарыбыз белән гәпләшәбез. Көнбагыш чиртә-чиртә, сагыз чәйни-чәйни.

Менә бу урында минем гел телевидениене гаеплисем килә. Ник сез безгә гел шундый коточкыч хәлләрне генә күрсәтәсез? Һәртөрле фаҗигаләр, аварияләр, янгыннар, кризислар – Русиянең язмышы ул, монда хакимият гаепле түгел дип әйтергә телисезме? Безгә ниндидер фикерне сеңдерергә итәсезме?

Хәтта телевидение генә дә түгел, барлык матбугат чараларын гаеплисем килә. Гәзитләрне, журналларны… Кайсын карама – юл һәлакәте, янгын, фаҗига, җинаять… Кан, үлем, азгынлык…

Гадәттән тыш хәлләрне исәпкә алмасак та әле… «Гадәти фаҗига» дип әйтимме соң инде… Ну, ел саен була торганнары… Россиядә ел саен 30 мең кешене үтерәләр, 30 меңе – юл һәлакәтендә, 15 меңе – батып, 40 меңе – эчеп, 20 меңе – янып, 20 меңе – грипптан, 300 меңе – рактан, 5 меңе СПИДтан үлә. 30 меңе хәбәрсез югала. 50 меңе үз-үзенә кул сала. 1,6 млн аборт ясала. Моңа әле армиядә үлүчеләр санын, көчләнүгә дучар булучы балаларны, хезмәт урыннында үлүчеләрне өстәргә мөмкин. Әллә күпме фаҗигаләр, үлемнәр, җинаятьләр табарга була. Алар хакында җентекләп сөйләргә, һәр детален зур планга алып күрсәтергә мөмкин… Һәм шул рәвешле ел әйләнәсенә дәвам итәргә.

Матбугат чараларын гаеплисем килә дә – гаепли алмыйм. Әйе, үзем бу өлкә белән бәйләнештә булган өчен дә. Журналист яңалык эзли, яңалык сөйли, күрсәтә, яза… Әгәр поезд билгеләнгән урынга барып җиткән икән, бу – яңалык була алмый. Әгәр ул рельслардан чыгып тәгәрәгән, шартлаган, якындагы авыл аша узган һәм бик күп кешеләрнең һәлакәтенә сәбәпче булган икән, бу – яңалык. Бу хакта берничек тә язмый кала алмыйсың. Һәм бу хәлләрне матбугатта чагылдырган өчен журналистны гаепләп тә булмый.

Икенче ягы да бар. Үз вакытында һәм җентекле яктыртылган фаҗига – басманың рейтингы ул. Караучылар, укучылар, реклама бирүчеләр саны. Димәк, бу – редакция өчен тираж, рейтинг, бер сүз белән әйтсәк, акча китерүче күренеш.

Һәм менә инде иң кызык урынына да килеп җиттек бугай. Мин – журналист, әгәр сез теләмисез икән, берниди фаҗига, үтереш, азгынлык турында да язмыйм да, аны күрсәтмим дә. Мин сез теләгән нәрсәләрне яктыртам: алдынгы малчы тормышын сурәтлим, озак еллар буена тату яшәгән гаилә турында сөйлим, герой ана турында… Телисезме?!

Ә сез теләмисез. Махсус эзләп карадым, өстә телгә алынган темаларга язмалар интернетта юк диярлек. Булса да, аларның рейтингы бик түбән, караучылар саны бик аз. Ә фаҗигаләр, аварияләр, үлемнәр, адәм кыйнау күренешләре… Мондыйларның күрергә теләүчеләрнең чиге-чамасы юк.

«Шундый кансыз күренешләрне күбрәк күргән саен, кешенең хис-тойгысы тупаслана, явызлык аның өчен нормага әверелә», – дип борчылабыз инде без.

Үсмер чакта караган бер фильмнан шундыйрак күренеш хәтердә калган. Исемен хәтерләмим инде. XIX гасыр. Кыш. Халык җәза мәйданына җыелган. Калтыраныл басып торалар, көтәләр. Кемнедер асарга тиешләр икән. Ну, алып чыгалар теге гаепле кешене. Башына кара капчык кидерәләр. Аяк астындагы нәрсәне алалар. Бәтте. Һәм шунда фильм героинясы, «аһ» итеп, күзләрен каплый. Фильмны мин аңламаганмындыр инде. Миндә: «Соң, күрәсең килмәгәч, ник шул гомер көтеп тордың соң?» – дигәнрәк сорау туганы истә. Ә бит элекке дәверләрдә мондый күренешләр бик табигый булган. Мәйданда кемнедер асалар, кисәләр, аталар икән – моны тамаша кылырга халык җыелган. Мондый нәрсәләргә концерт, театр яки циркка йөргән кебек йөргәннәр.

Марат КӘБИРОВ

Бәлки, моңа аптырарга кирәкмидер. Без, әлбәттә, кеше дигән затны күкләргә күтәрәбез. Ә биологик яктан караганда, сөтимәрләрнең бер төре бит инде ул. Һәм ит ашаучы сөтимәр. Печән ашаучы гына түгел. Ә ит ашау өчен яки үзеңә кемнедер үтерергә, яки үләксә эзләргә кирәк. Бер сүз белән әйткәндә, ерткыч булырга.

Адәм теленә күчерсәк, һәртөрле фаҗигаләрне, үлем-китемнәрне тамаша кылырга яратуы – адәм баласының бозыклыгы түгел, ә бары тик аның табигый ихтыяҗларын канәгатьләндерү генә булып чыга. Ну, кирәк аның организмына шушындый коточкыч тамашалар. Бу ниндидер гормоннар бүлеп чыгара, үз тормышындагы куркыныч вакыйгаларга тынычрак карарга, аларны салкын кан белән җиңеп чыгарга булыша. Белгечләр шулай ди.

Шулай да… берәр малчы турында язасы, аны, сарык бәрәне тоттырып, фотога төшерәсе килә… Бу минем бозыклыктан түгел, ә кешенең табигый ихтыяҗлары турында уйлаудан. Ну, кирәктер кебек аның организмына шундый самими күренешләр…

Кирәк микән? Сокландырыр иде микән? Аппетитын гына кузгатмас микән?

«Картаясым килми»

Башкортстанның Сибай шәһәрендә яшәүче 56 яшьлек Роза Гарифуллина шпагатка утыра, хип-хоп, брейк-данс бии, оныклары белән футбол уйный, көнөнә алтышар сәгать фитнес клубта дәресләр алып бара.

– Син кайчан картаерга уйлыйсың инде, дип сорыйлар миннән. Картаерга вакытым да, теләгем дә юк. Башкаларга да шуны киңәш итәм. Күпләр пенсиягә чыгу яшен көтеп-көтеп алалар, анналы нәрсә? Тормыш дәвам итә, күрә белгән кешегә ул тагын да кызыклырак әле. Яшеңне санарга, көзге каршына басып, җыерчыкларыңа карап күңелсезләнергә кирәкми. Яратыгыз үзегезне, яратыгыз тормышны. Пенсионер яки әби булу ул картлык түгел, ә яңа статус, дип күңелләрен күтәрәм спорт белән шөгыльләнергә килүчеләрнең. Пенсиягә чыккач, киресенчә, үзеңне карарга вакыт табыла, – ди картаюны белмәс яңа танышым.

Аның сүзләренчә, спорт ул, беренче чиратта, сәламәтлек.

– Йөгерүме, велосипедта йөрүме, шейпинг, пилатес, тренажер залымы, аэробикамы – аның сы мөһим түгел, шөгыльлән генә. Мин үземнең соңгы тапкыр сырхауханәдә кайчан булуымны да онытттым инде, – дип елмая ул. – Спорт белән шөгыльләнергә яратмаучылар алар, дәресен генә әйткәндә, ялкаулар. Минем бу сүзләремә беркем дә үпкәләмәстер, киресенчә, аларга уйланырга бер этәргеч булыр.

– Спорт белән шөгыльләнергә сезне тагын нәрсә рухландыра?

– Оныкларым, алар янында гел авырудан зарланган, бетәшкән бер карчык кебек күренәсем килми. Кирәк икән тубын да тибәм, велосипедта да ярыша алам, походка да чыгабыз.

Спорт белән шөгыльләнү генә түгел, сәламәт туклану ягында да ул. Баллы, майлы, тозлы ризыкларны ашамаска тырыша, йоклар алдыннан ашауны бөтенләй өнәми. Төнлә соң ятса да, иртәнге сигездә торырга күнеккән. Торуга, бер стакан су эчә.

– Кәефем гел күтәренке булу, энергиям ташып торуның тагын бер сәбәбе, мөгаен, яшелчә һәм бигрәк тә сельдерей ашаудадыр. Диета тотканым юк, сәламәт туклануга күчкән кешегә аны кирәк дип тә уйламыйм, – ди ул.

Роза Захаровна – белгечлеге буенча укытучы, 2005 елда «Ел укытучысы» исеменә дә лаек булган.

– Картлык – шатлык түгел дип зарланып утырырга түгел, аны шатлыкка әйләндерергә кирәк. Һәр чорның үз матурлыгы, сөенече бар, – ди ул.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

«ШӘҺРИ КАЗАН»нан – алма бакчасы

Бу язылу кампаниясендә укучыларыбызны нинди бүләк белән сөендерик икән, дип озак уйландык. Үзе файдалы да, истәлекле дә, матур да булсын иде ул бүләк. Уйлый торгач таптык тагын: без сезгә, Югары Ослан районының Ямбулат авылындагы «Заря» питомнигы белән берлектә, алмагач үсентеләре бүләк итәбез!

Бүләк алуның әллә ни кыенлыгы юк. Газетадагы анкетаны тутырып, 2017 елның II яртыеллыгына язылу турындагы квитанцияне редакциягә җибәрергә һәм жирәбә нәтиҗәләрен генә көтәргә кирәк. Үзегезгә ничек җайлы, шулай эшләгез, без аларны почта аша да, электрон адресыбызга да, «ватсап» аша да, социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә дә кабул итәбез. Бүләк ике атна саен уйнатылачак, беренче үсентеләрнең хуҗаларын инде 26 апрельдә үк ачыклаячакбыз. Жирәбә уйнатуны видеога төшереп, www.shahrikazan.com сайтында урнаштырачакбыз.

Әйдәгез, алма бакчасында «Шәһри Казан» укыйк әле!

ИНДЕКСЛАР

П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **401 сум 94 тиен.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **816 сум 90 тиен.**

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон___

2. Яшегез___

3. Шөгылегез___

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз?___

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз?___

6. Газетага ничек язылсасыз:

почта бүлекчәсендә ___

хат ташучы өйгә килә ___

интернет аша ___

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз?___

8. Сезне нинди эчтәлектәге язмалар җәлеп итә?___

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез?___

10. Газетаның миңа иң ошаган:___

ошамаган яклары:___

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз?___

Языл → **Анкетаны тутыр** → **Җибәр**

«Шәһри Казан» газетасына почта бүлекчәләрендә яки интернет аша языл

Анкета, квитанцияләр, «Алмагач» дигән тамга белән, түбәндәге адресларга кабул ителә:

Почта аша: 420066, Казан, Чистай урамы, 5нче йорт, «Шәһри Казан» редакциясе

Электрон почта: shahri-kazan@tatmedia.com

Ватсап: 8 917-851-69-62

Социаль челтәрләрдәге төркемнәр: vk.com/shahrikazanda facebook.com/shahrikazan ok.ru/shrikazan

Газетага ничек язылырга?

1. ТАТАРСТАННЫҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ПОЧТА БҮЛЕГЕНДӘ

2. Казан шәһәрендә өегезгә дә килеп яздырабыз. Моның өчен **562-50-12** яки **8-917-851 69 62** номерларына шалтыратып, заявка калдырырга кирәк

3. ИНТЕРНЕТ АША – ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ПОРТАЛЫНДА

Моның өчен кул астында интернетка тоташкан берәр җайланма булуы гына кирәк

1. uslugi.tatarstan.ru сайтына кер;

2. «Подписка: газеты и журналы» дигән төймәгә бас;

3. Шәхси кабинетыңа кер;

4. **«Шәһри Казан»** (электрон каталогта – «Шахри Казан») газетасын сайла;

5. Адресыңны яз;

6. Дәүләт хезмәтләре порталы аша квитанцияне түлә.

Реклама

Тулырак мәгълүмат shahrikazan.com сайтында

«Рухият» рухи яңарыш фондының башкарма директоры **Флюра ШӘЙХЕТДИНОВА:**

– 20 ел – юбилей түгел. Ул бары тик бик әһәмиятле вакыйга гына. Шушы түгәрәк дата артында педагогларның, жюри әгъзаларының, сәләтле балаларның никадәр тырышлыгы ята. Ил икътисадында авыр еллар булса да, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең «Рухият» фонды бервакытта да проблемалар кичермәде. Эшләребез һәрчак алга бара. Һәм үз чиратында балалар да лаеклы чыгышлары белән сөендерә. Узган ел безнең фонд Россия Грантына ия булды. Владимир Спиваков исемендәге Халыкара хәйрия фонды белән берлектә, «Балалар – балаларга» проектын гамәлгә ашырдык. Бездә чыныгу алган «сандугач»лар хәзер Россия дәрәҗәсендәге бәйгеләрдә катнаша. Шундыйлардан берсе – Азнакай егете Газинур Равилов В.Спиваков фондының грантына ия булды.

«ТАТНЕФТЬ» сандугачлары

Фоторепортаж www.shahrikazan.com сайтында

«Рухият» рухи яңарыш фондының «Сандугач сайрар илем» балалар иҗаты фестивале үзенең егерменче – юбилей сезонын һәрвакыттагыча Казанда зур гала-концерт белән тәгәлләде. Бу көнне Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе сәхнәсендә 300гә якын «сандугач» чыгыш ясады.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Зөһрә САДЫЙКОВА

«Татнефть» акционерлык җәмгыятенең «Рухият» рухи яңарыш фонды фестивале ел саен әнә шулай нефть төбәгендә яшәүче сәләтле балаларны һәм яшүсмерләрне бергә туплап, аларга канатлар куя, тормышларын мәдәният белән бәйләүче яшьләргә ярдәм итеп килә. Быел да фестивальдә барлыгы 2 мең чамасы бала үзен 17 номинациядә күрсәткән. Сайлап алу турлары 15 шәһәр һәм районда узган елның ноябреннән башланган иде. Анда исә җиде номинация генә калдырылган: «Вокал-соло», «Вокал-ансамбльләр», «Халык уен кораллары», «Фортепиано», «Рәсем сәнгате», «Сәнгатьле уку», «Хореография». Ә артта калган елларга күз ташласак, егерме ел эчендә «Сандугач сайрар илем» бәйгесе 22 нефть төбәген берләштергән. Башка бик күп фестивальләрдән аермалы буларак, биредә катнашучы балаларның сайлап алу турлары сәламәтләндерү лагерьларында уза.

«Рухият» фондының башкарма директоры Флюра Шәйхетдинова әйтүенчә, быелгы фестивальнең яңалыгы-үзенчәлеге – лауреатлар өчен 1-3 мең сум акчалата премияләр тапшыру. Ә фестивальнең асылташлары берничә елга бер тапкыр гына бирелә торган Гран-прига ия була. Быел алар икәү иде – «Азаль» вокал-хореография ансамбле (Зәй шәһәре) һәм «Мириданс» халык бию ансамбле (Әлмәтнең политехник техникумы). «Татнефть» җәмгыяте аларга 25 мең сум күләмендә акчалата бүләкләр дә әзерләгән. Моннан кала, «Татнефть»нең тагын бер күркәм гамәле – тормышларын мәдәният, сәнгать юлыннан дәвам итәргә карар кылган студентларга елына 12 мең сум күләмендә стипендия дә билгеләү. Канатларын ныгыткан «сандугач»ларны әнә шулай алга таба да тәрбияләп, үсендереп тору, уңышларын күрә һәм бәяли белү дә бик зур хөрмәткә лаеклы эш шул.

«Сандугач сайрар илем» фестивалендә «канат чыгарган» сәләтле яшьләр алга таба Татарстанның мәдәният өлкәсендә лаеклы урыннарны били. Татарстанның атказанган артистлары Айдар Сөләйманов, Эльмира Кәлимуллина, Наил Сәгъдиев, Казан дәүләт консерваториясе доцентлары Антон Попов, татар эстрадасының популяр артисты Мөнир Рахмаев, танылган җырчылар Алина Прокофьева һәм Азат Кәримовлар – әнә шундыйлардан. Шулай ук алар арасында укуларын Гнесиналар исемендәге Россия музыка академиясендә, Нәҗиб Җиһанов исемендәге консерваториядә дәвам итүчеләр дә бар. Бер ел элек кенә армия сафларыннан кайткан Артем Ивов дигән егет Александров исемендәге җыр һәм бию ансамблендә хезмәт иткән. Туган якларына әйләнеп кайкач та ул укуын консерваториядә дәвам итә.

Концерт барышында аларга әлеге бүләкләрне «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директорының урынбасары, «Рухият» фонды советы рәисе, Татарстанның Дәүләт Советы депутаты Рөстәм Мөхәммәдиев тапшырды.

– Быел «Рухият» фонды оешуга 20 ел тулды. Шушы матур сәхнәдән аның чишмә башында торган кешеләргә – фондның төп оештыручысы һәм беренче башкарма директоры Илсөяр Хәйруллинага, ул вакытларда «Татнефть»нең генераль директоры булган Ринат Галиевкә һәм фестивальнең бүгенге җитәкчесе Флюра Шәйхетдиновага, сайлап алу турлары төрле шәһәрдә узса да, һәрвакыт сәләтле балаларга бәя биргән жюри әгъзаларына, педагогларга, әтиәниләргә һәм Татарстанның Мәдәният министрлыгына зур рәхмәт сүзләрен җиткерәсе килә. Нинди генә мәйдан сорасак та, алар һәрвакыт безгә теләктәшлек күрсәтеп килә. Безнең балалар Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында, УНИКСта, Г.Камал театры сәхнәсендә, «Пирамида»да чыгыш ясады. Һәр кешенең эш нәтиҗәсен бүген күрә һәм бәяли алабыз – менә бит балалар ничек лаеклы чыгыш ясый. Белгеч түгелмен, әлбәттә, әмма, минемчә, алар инде ярымпрофессиональ дәрәҗәдә иҗат итә. Тормышларындагы шушы матур мизгелләр аларның күңелләрендә мәңгегә сакланачак, – диде ул.

Фестивальдә катнашучыларны Татарстанның мәдәният министры урынбасары Светлана Персова һәм Владимир Спиваковның Халыкара хәйрия фондының Башкортстандагы директоры, Мәскәү филармониясе солисты Артур Назиуллин да котлады. Флюра Шәйхетдинова әйтүенчә, Әлмәттә оештырылган гала-концерттан соң балалар Казандагы тамашаны бик зур түземсезлек белән көтеп ала.

– Бик күп танылган җырчылар, атказанган һәм халык артистлары чыгыш ясаган сәхнәдә үзеңне күрсәтә алу – балалар өчен бик зур дәрәҗә һәм бәхет. Шунысын да әйтәсе килә: без бер генә конкурс белән дә ярышмыйбыз. Татарстанда оештырыла торган һәр бәйгенең үз юлы. Безнең бурыч – милли рухны саклап калу. Шуңа күрә әлеге концертта да халык көйләренә, халык җырларына, биюләренә, классик музыкага зур урын бирелде, – диде безгә Флюра ханым.

АШ БУЛСЫН

«ВИОЛЕТТА» салаты

3 пешкән чөгендер, 3 тозлы кыяр, 3 аш кашыгы яшел борчак (консервланганы да ярый), 1 йомшак сыр (әйтик, «Дружба» сыры), 1 тырнак сарымсак, майонез

Чөгендер, кыяр, сырны шакмаклап турарга, сарымсакны угычта уарга, яшел борчак һәм майонез кушып болгатырга.

СӘЛАМӘТЛЕК

КИҢӘШ САНДЫГЫ

Ашказаны-эчәклек тракты эшчәнлегенә нәрсә комачаулый?

✓ Дөрес тукланмау – ризыкны озаклап чәйнәп тормыйча йоту, артык кайнар яки салкын ризык ашау, ачы тәмләткечләр күп куллану.
✓ Туклану режимы бозылу – күп ашау, ашау вакытларының арасы зур булу, коры-сары белән туклану.
✓ Ашаганда сыеклык эчү – ашкайнату процессын боза.
✓ Соң ашау – көндез ашарга вакыт таба алмыйча, кичен күп итеп ашау.
✓ Стресслар, арыганлык.
✓ Эчәклек микрофлорасы бозылу, ягъни дисбактериоз.
✓ Дарулар күп «ашау».
✓ Зарарлы гадәтләр – тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр, каһвәне күп эчү, фаст-фуд белән туклану.

Суны дөрес эчкәндә файдасы да зур була

- Йокыдан уянгач ике стакан су – эчке органнар эшчәнлеген активлаштыра.
- Ашарга ярты сәгать кала бер стакан су – ашкайнату процессын яхшырта.
- Ванна керер алдыннан бер стакан су – кан басымын төшерергә булыша.
- Йоклар алдыннан бер стакан су – инсульт булу куркынычын киметә.

КЕШЕНЕҢ ТОРМЫШ ЭНЕРГИЯСЕ ЮГАЛА:

× «юк» дип әйтәсе килгәндә, «әйе» дисә
× елыйсы килгәндә, елмайганда
× ял итмәгәндә
× кемгә дә булса үпкәләгәндә
× яратмаган эшендә эшләмәсә
× үзен мәҗбүриләп, теләмичә аралашканда
× сәясәт, коммуналь хезмәтләр тарифлары турында сөйләшкәндә
× гайбәт сатканда
× үз-үзен битәрләгәндә
× үзен бәхетсез итеп тойганда

ТОРМЫШ ЭНЕРГИЯСЕ АРТА:

✓ яңа кешеләр белән танышканда
✓ яңа белемнәр алганда
✓ сәяхәт иткәндә
✓ куркуны җиңгәндә
✓ яңа шөгыль тапканда
✓ иҗат белән шөгыльләнгәндә
✓ спорт белән шөгыльләнгәндә
✓ йокы туйганчы йоклаганда

БЕЛЕП ТОР!

Тиз өлгерә торган камыр

Кунаклар килгәч, тиз генә камыр ашы пешерергә уйласагыз, әлеге рецептны кулланыгыз. Тәме дә искиткеч була.

1 стакан кайнар суга 1 стакан салкын сөт, 0,5 стакан үсемлек мае (чистасы), 1 бал кашыгы тоз, 1 аш кашыгы шикәр комы һәм 1 пакет (11 граммлы) «Саф момент» чүпрәсен салып, яхшылап болгатасың. Аннан соң 5 стакан он салып басасың, тик 5нче стаканны салып ук бетермичә, иң элек камырның тыгызлыгын карарга кирәк (артык каты да, йомшак та булмасын). Аннан соң тишек булмаган целлофан пакетка тутырып, пакетның очыннан гына һава кермәслек итеп бәйлисең дә суыткычның өске киштәсенә куясың. Чүпрәсе яхшы булганда, 40 минутта кабарып менә. Бик юка итеп җәелә, пицца пешерергә дә, пирогларга да менә дигән камыр. Икенче көнне дә йомшак тора. Бер-ике пешергәч, бүтән төрле камыр куярга теләгегез дә булмас. Ашларыгыз тәмле булсын.

Бакчачыга

СУГАН УТЫРТУ СЕРЛӘРЕ

Суганны утыртыр алдыннан өч сәгать тозлы суда тотыгыз (бер литр җылы суга бер аш кашыгы). Аннары юып, ике сәгать марганцовка эремәсендә тотып алыгыз. Тагын юып, аз гына киптереп аласы да дымлы түтәлгә утыртасы. Өстенә бераз ком сибегез.

БОЛГАР БОРЫЧЫ ЭССЕ ЯРАТА

✓ Болгар борычы үсә торган теплицада яңгырлы көндә – 22-24 градус, кояшлы көндә – 24-28 градус, ә төнлә 18-20 градус эсселек булырга тиеш.
✓ Аларга җылы су сибәргә тырышыгыз. Атнасына бер-ике тапкыр һәр төпкә кимендә 1-2 литр су сибегез.
✓ Аена ике тапкыр һәр үсенте төбенә бер аш кашыгы көл сибегез. Икенче көнне туфрагын йомшартыгыз.

ХУҖАБИКӘГӘ

Җиләк-җимештән ассорти



ФАЙДАЛЫ

Язын витамин аша

- Яз белән бергә авитаминоз да килә, димәк, яшелчә, җиләк-җимеш, яшел тәмләткечләрне күбрәк ашарга кирәк.
- Укропның яфракларында B_1, B_2, С, РР, Р витаминнары, каротин, фолий кислотасы, тимер тозы, фосфор, кальций һәм калий бар. Ул шулай ук эфир майларына бай. Укроп кан тамырларын киңәйтә, кан басымын төшерә.
- Петрушка – иң популяр һәм иң файдалы тәмләткеч. Аңарда кальций, магний, тимер, калий, фтор һәм фосфор бар. Йөрәк авыруларыннан җәфаланучыларга аны күбрәк ашарга киңәш итәләр. Ул пародонтоз вакытында да файдалы.
- Яшел суганда исә цинк, кальций, фосфор күп, шуның белән ул сөякләр өчен файдалы. Суган иммунитетны яхшырта, йөрәк-кан тамырларын ныгыта.
- Яфраклы салат кан составын, матдәләр алмашын яхшырта, ашкайнатуны тизләтә, нерв системасын тынычландыра, кан басымын төшерә, организмнан начар холестеринны чыгара.
- Сельдерей – сәламәтлек өчен иң куркынычсыз тәмләткеч. Аңарда С витамины, кальций тозы һәм фосфор бар. Ул картаю процессын акрынайта, матдәләр алмашын яхшырта, артык гәүдә авырлыгыннан котылырга булыша. Сельдерей тамыры магний, кальций, калий, марганец, тимер һәм цинкка бай. Аны шакмаклап турап яки угычта уып, салатларга кушалар. Пешкән сельдерей тамыры бәрәңгене хәтерләтә.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА
әзерләде.

Дәвалаучы Зөһрә Айнулина:

«ЯХШЫ УЙДА БУЛЫГЫЗ!»

Зөһрә Айнулина үзен дәвалаучы, Ходай белән Адәм арасын тоташтыручы дип таныштырды. «Тере энергия» ярдәмендә, тәннән бигрәк, җанны сихәтләндерәм, дип тә өстәде. Зөһрә ханым – Себер татары. Яшәве дә Төмәндә, Казанга ике-өч айга бер мәртәбә килеп, кешеләрне дәвалый икән.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КЫЗЫК КЕШЕ

– Әлеге сәләтем буыннан буынга тапшырылып, нәселдән килә, – дип, сүзен үзе белән таныштырудан башлады ул. – Бабамның әтисе Хәмитулла Айнуллин кешеләрне Коръән ярдәмендә дәвалаучы бик көчле, якты кеше булган. Аның җәяүләп хаҗга баруы белән чиксез горурланам. Кызганычка, мин аны хәтерләмим. Әмма язмышымда дәү бабамның роле гаять зур икәнлеген беләм – миңа исем бирүче дә, тормышымны алдан күреп юраучым да ул. Гомумән, безнең нәсел бик көчле. Һәм әлеге сәләт миңа әти ягыннан да, әни ягыннан да килә. Бабам Себердә укыткан. Сугышка киткәнче, шулай ук кешеләргә ярдәм иткән. Әтием Изл урамда ярдәмгә мохтаҗ кешене очратса, аны өйгә алып кереп, ашатаэчертә, киендерә торган иде. Әни ягыннан бабамнар мәчет саклаучылар булган. Туганнарым арасында да мулла һәм Коръән белән дәвалаучылар бар. Балаларыма да бирелгән бу сәләт, тик улым аны кабул итәргә генә әзер түгел. Кызымның өч баласы бар. Игезәкләре бик нечкә тоемлый. Гомумән, кешеләргә ярдәм итү – безнең каныбызда. Шулай да нәселебез бик көчле булса да, сәләт һәр яклап агылса да, кешеләрне дәвалаячагымны кечкенәдән үк белсәм дә, шуны үземдә сынап караганчы, бик озак карыштым. Чөнки бу – йөрәкләрне ачучы, кешеләрнең язмышларын үзгәртүче бик җаваплы эш. Миңа кадәр бертуган абыем булыша иде кешеләргә. Шунлыктан гаиләдәге ике кешенең дә дәвалаучы булуы мәҗбүри түгел, дип уйлый идем. Әмма бу дөньяга менә шулай кинәт килеп кермәс өчен, алданрак шөгыльләнергә кирәк булган икән. Ныклап торып абыем вафатыннан соң гына шөгыльләнә башладым. Хәзер инде Ходай биргән бу сәләттән баш тарта алмыйм. Кешенең тормышы төптән үзгәрүен күреп, бик сөенәм. Хәтта мин аларның үзләренә караганда да ныграк шатланамдыр әле.

– Кешеләр сезгә нинди проблемалар белән килә?

– Элек авыруларны сихәтләндерә идем, хәзер кеше күңелен дәвалыйм, эчке мөмкинлекләрен ачам. Бүген күпләр рухи яктан үсеш кичерергә тели. Аларга «Бу дөньяга ни өчен килдем?», «Ни өчен яшим?» дигән сораулар тынгылык бирми. Мин шундыйларга «ачылырга», күңелләрен, әйләнә-тирә мохитен чистартырга ярдәм итәм. Минем янга балага уза алмаган хатын-кызлар, озак вакыт дәвамында депрессиядән интеккән, гаилә кора алмаган кешеләр күп килә. Әни булырга хыялланган хатын-кызлар «Ни өчен?», «Кайчан?» кебек сорауларга җавап табарга тели. Мин шушы сорауларны төзәтеп, кешенең уйларын дөрес юлга борам. Әлбәттә, кемдер тиз, кемдер соңрак ана булу бәхетен татый. Әмма нәтиҗә һәрвакыт бар. Моның өчен, әйткәнемчә, кеше үзенең уйларын, күңелендәге мәгълүматны уңай якка үзгәртергә тиеш. Бала – Аллаһы Тәгаләнең олы бүләге. Шуны чын күңелдән аңларга кирәк. Элек наркоманнарны һәм эчкечеләрне дәвалый идем, хәзер алар белән шөгыльләнмим. Чөнки бу бәладән авыру үзенүзе генә коткара ала. Наркомания һәм эчкечелекне көчләп дәвалап булмый. «Мин ни өчен эчәм?», «Кайда һәм кайчан ялгыштым?» – башта менә шушы сорауларга җавап табылырга тиеш. Эчкечеләр арасында тормышның иң төбенә төшеп, яхшы кешеләр булып күтәрелүчеләр дә, дин юлына басучылар да бар.

– Сез үзегезне «тере энергия» белән дәвалаучы дип таныштырдыгыз. Нәрсә соң ул «тере энергия»?

– Мин махсус дога укып, үз каналларым аша кешенең күңелен «ачам» һәм «тере», «җанлы энергия» белән эшлим. Тәннең һәр күзәнәгә сизәрдәй рәхәт җылылык тарала. Кояш нурлары кешене ничек җылыткан кебек, энергия да күңелне һәм җанны шулай җылыта. Тик аның белән бик сак эш итәргә кирәк. Дөрес кулланмаган очракта, кеше авыруга сабышырга мөмкин. Әлеге энергия үзе белән начар мөнәсәбәттә булуны яратмый. Тере энергия ярдәмендә, кеше үз-үзен дә дәвалый ала.

– Кеше үе бик күп нәрсәгә сәләтле икәнен психологик китаплардан укып беләбез. Сезнең дәвалау методикасында да шушы идея алга сөрелә кебек.

– Әйе, чыннан да, кеше тискәре, начар уйларга бирелеп, үзе дә сизмәстән, шуларны үзенә тарта. Мәсәлән, бер авыру билгеләре турында китаптан укый да шуларны үзендә эзли башлый. Үз-үзен ашый, эчтән «кимерә». Яки берәр эшкә тотынганчы, «Бу эшем барып чыкмас микән» дип уйлый һәм үзе дә сизмәстән, хезмәтен тискәре нәтиҗәләргә программалаштыра. Мин исә кешеләрнең уй-фикерләрен, тормышка карашларын уңай якка үзгәртергә ярдәм итәм. Адәм баласы дөньяга көенеч өчен түгел, ә сөенеч өчен килүен аңларга тиеш. Депрессия белән авыручылар күп килә дидем. Күптән түгел генә бер ханым белән очрашырга туры килде. Ире белән аерылышуны бик авыр кичергән, тормышының мәгънәсе югалган. Тирән депрессия кичерә иде. Бер сәгать дәвамында яхшылап эшләргә туры килде аның белән. Шуннан соң икенче кеше булды да куйды. Читекченең читеге юк, диләр бит әле. Миңа да соңгы вакытта психологлар еш мөрәҗәгать итә башлады, чөнки алар кеше проблемаларын үзләренә «сеңдерә». Әгәр кеше үзгәрергә теләк белдереп мөрәҗәгать итә икән, мин аның аурасын, тышкы «кабыгын» чистарта башлыйм. Сеанслардан соң кеше сәламәт тәндә яңадан туа. Бу халәттән чыкканнан соң алар, сабый бала кебек, ничек атлап китәргә, авыз ачып сүз әйтергә белми тора. Кешенең күңеле, эчке халәте чистармыйча, ул үзенә яхшылык җәлеп итмәячәк. Чүп чиләгеннән чәй эчмибез бит. Монда да шулай ук.

– Чистарыну дигән сүзне телгә еш аласыз. Чын дөреслектә ничек аңларга соң аны?

– Бөтен начар уйлардан чистарыну дигән сүз ул. Мин кешенең аурасын (тышчасын) чистарткач, бөтен тишекләрен ямагач, күзләре яктырак яна башлый. Күңелен рәхәтлек, тынычлык били. Шуңа күрә кешеләрнең тагын да ныграк ачылуларын, уянуларын телим. Дөрес сулау, медитация, дога ярдәмендә дә кеше үзен һәм башкаларны чистарта ала. Шулай ук кеше күңеле Рамазан аенда дога, теләкләр, ураза тоту ярдәмендә дә чистарына.

– Газета укучыларыбызга нинди теләкләр җиткерәсегез килә?

– Яхшы уйда булыгыз! Мәхәббәт, шатлык белән уңай, позитив хәлләр турында гына уйлагыз. Без, магнит кебек, һәр нәрсәне үзебезгә тартабыз. Уебыз яхшы икән, үзебезгә дә яхшы хәбәрләр генә киләчәк. Билгеле бер вакытта башыгызга, уегызга бернинди дә яхшы фикер килмәгән очракта да – елмаегыз. Урамда таныш булмаган бер кешегә елмаю бүләк итү дә күп нәрсәне үзгәртә. Яз килде, җир уяна, кошлар сайрый, кояш яктырта – тормыштан ләззәт алыр өчен никадәр сәбәп бар бит!

АККОШЛАР МӘХӘББӘТЕ... МӘҢГЕЛЕК ТҮГЕЛ

БУ – КЫЗЫК!

Ни өчен аккошлар мәхәббәт символы санала, нишләп орнитологлар бала чыгармаучы күкене хөрмәт итә, сыерчыкларның саны нигә азайган? Орнитолог, биология фәннәре докторы Илгизәр Рәхимов белән әңгәмәбез барышында тагын бик күп сорауларга җаваплар таптым.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Илгизәр Ильясович, сез кошлар турында бик озаклап, тәмле итеп сөйләргә яратасыз, орнитология белән кызыксынуыгыз кайчан барлыкка килде?

– Бала вакыттан ишегалдындагы кош-кортлар, мәче, этләр минем дуслар иде. Песнәк баласын да, карга баласын да күтәреп кайтканым булды. Бөҗәкләр дә игътибардан читтә калмады. Гаиләдә бер генә бала булгач, әни моны миңа иптәш булмаудан күрде, дәшмәде, түзде. Мәктәпне тәмамлаганда ук үземнең биолог буласымны тәгаенләп куйган идем. Шул елларда, Советлар Союзында иң беренче буларак, Казанда табигатьне саклау кафедрасы ачылды. Анда конкурс югары булды, «бишле»ләр белән генә кабул иттеләр. Ә минем бер имтиханым «дүртле» булды, укырга керә алмадым. Армиядән кайткач, тагын кереп карадым – ике «бишле», ике «дүртле» алдым, бу юлы да кабул итмәделәр. Аннары рабфакта укып алып, ниһаять, студент булдым. Кафедра мөдире Виктор Поповта укуым белән бәхетлемен, аның дәресләре бик кызыклы үтә иде, үзенең фәненә карата бездә мәхәббәт уятты. Орнитология ул – бик мавыктыргыч фән. Республика буенча кошларның 300дән артык төре бар, ә Казанда 200 төрдәге кош яши. Өйрәнү өчен аларның һәммәсе кызыклы.

– Иң кечкенә һәм иң зур кош дип кайсыларын әйтер идегез?

– Иң зурысы – бөркет, иң кечкенәсе – кычыткан чыпчыгы. Иң озын гомерлесе – козгын. Ул йөз елга кадәр яши, диләр. Әмма бу факт ачыкланмаган, замокларда яши торганы, бәлки, озак та яшидер, аларны ашаталар, шартлар яхшы. Ә табигатьтә яши торганнары алай ук озын гомерле булмыйдыр.

– Җылы яктан күчмә кошлар да кайтып җитте, алар кыш чыгарга Африкага кадәр очып китәләр икән?

– Бытбылдык белән керәшә Африкага оча. Чәукәләр, карлыгачлар, сандугачлар, сыерчыклар, үрдәкләр Европа илләренә, әйтик, Италия, Испания, Франциягә китә. Чинар чыпчыгы (зеленушка) Кытайга ук юл тота. Көн әйбәт булса, мең чакрымны алар бер атнада үтә. Эсседә очмыйлар, иртән һәм кичен хәрәкәт итәргә тырышалар. Керәшә, карлыгачлар тизрәк оча, бу араны берничә көн эчендә үтәләр. Ерткыч кошлар вак кошларга караганда тизрәк оча.

– Алар юлда ничек бер дә адашып калмыйча, үз туган ояларын эзләп таба?

– Кошларда, безнең белән чагыштырганда, ориентация механизмы көчле. Аларның баш миләрендә, гади генә итеп әйткәндә, компас бар һәм ул магнит кырын сизеп тора. Без дә беләбез ул магнит кыры барлыгын, әмма аны тәнебез белән сизмибез. Ә кошлар сизә. Шуңа таянып, алар беркайчан да адашмый, төнлә дә, яңгырлы көндә дә юлны табалар. Җил аларның көтүләрен тегендә-монда тузгытырга да мөмкин, әмма векторны табып, юлларын дәвам итә алалар.

– Климат җылыну аркасында, кайбер күчмә кошлар кышны бездә уздыра башлады. Алар салкыннарны исән-сау кичерәләрме?

– Кышларга калучы кошларның саны елдан-ел арта. Бу бөтен дөнья буенча шулай. Элек кыргый үрдәкләрнең бездә калу очрагы бөтенләй юк иде. Хәзер исә, кышлар җылы килгәч, күп кенә сулыкларны боз капламый, Болак та тоташ катмый. Аннары батарейлардан чыккан техник җылы су Кабан күленә, ТЭЦ янындагы күлгә агып чыга, боз катарга ирек бирмми. Үрдәкләр шунда рәхәтләнеп кышлый. Аларга суык куркыныч түгел, чөнки тән температуралары – 42 градус. Ә менә азык булмаса, кышны чыгарга бик авыр. Шуңа да бөҗәкләр белән тукланучы кошлар җылы якларга китәргә мәҗбүр. Ярма, җимеш, катнаш ризык белән тукланучылары, әйтик, чәүкә, саескан, кара каргалар исә бездә кышларга кала башлады, аларга азык табу авыр түгел. Көтүләре белән көне буе Самосырово чүплегендә эзләнеп тукланалар да кичкә паркларга кайтып куналар.

– Авыл халкы, чыпчыклар азайган кебек, ди...

– Алар хаклы, чыпчыклар кимеде. Без моны атлар киму белән аңлатып та карыйбыз. Элек авыл җирендә ат асрыйлар иде, чыпчыклар ат тизәгендә казынырга ярата бит. Сыер тизәге аларны кызыксындырмый, аның ашказаны дүрт камералы булгач, азыкны ахырга кадәр эшкәртеп бетерә. Ә атның ашказаны аша ярма бөртекләре бүртеп чыга. Чыпчыклар шуның белән туклана. Сыерчыклар да кимеде, чөнки аларга оя корырга урын калмады. Парк, зиратлардан иске агачларны кисеп алдылар, аларның куышларына кошлар оя кора иде. Сыерчык ояларын ясап элүчеләр дә сирәк. Элек 1 апрель – Бөтендөнья кошлар көнен зур бәйрәм кебек үткәрә идек. Әтиләр белән бергә кош оялары ясап элеп куюыбыз, аларны сыерчык килдеме икән дип күзәтеп торуыбыз истә. Кошлар көне уңаеннан бер мәктәпкә чакырдылар. Укучыларның әти-әниләре дә килгән иде. Укытучы, кошларга оялар элик, дигән тәкъдимен җиткерде. Бер әти кеше, мин оя каян алыйм, дисә, икенчесе, аны ясар өчен материал кирәк бит, үзем сатып алыймы, ди. Арадан берсе, әзер килеш кибеттә дә сатыла, дип куйды. Калганнар, аны үз акчабызга сатып алып куйыйкмы дип, мине шаккатырдылар. Кошларга оя ясау традициясе бетте хәзер. Булган оялар да череп бетте.

– Күгәрченнәрнең дә саны азайдымы?

– 2000 елларга кадәр Казанда уртача 700-800 мең күгәрчен бар иде, бүгенге көндә нибары 200-300 меңләп кенә. Аның сәбәбе берничә. Бердән, шәһәрдә яшәү өчен шартлар кимеде. Элек алар биш катлы хрущевкаларның чормаларында яшәде, бер йорт чормасында гына да 50дән артык оя иде ул вакытта. Хәзер йортлар биек итеп төзелә, күгәрченнәр ул биеклеккә кадәр менми, шуңа өстәп, ачык чормалары да юк, оя кора алмыйлар. Икенчедән, халык бик сакчылга әйләнде, каткан ипи кисәкләрен чүплекләргә чыгармый башлады. Димәк, аларга азык та юк. Өченчедән, үз чорында чебеш, каз бәпкәләренә тимәсен өчен, ерткыч кошларга, әйтик, тилгән, карчыгаларга актив ау оештырдык. Шәһәр эчендә алар калмады. Алар урынына каргалар килде, шул рәвешле аларның саны да артты. Каргалар исә күгәрченнәрне кырыштыра башлады. Әмма шунысын да әйтергә кирәк: азык булмагач, күгәрченнәр кимегәч, каргаларның да саны кимүне күзәтәбез. Җәй көне каргаларны, студентларга күрсәтер өчен, эзләп йөрергә туры килә.

– Илгизәр Ильясович, аккошларны мәхәббәт символы дип атау кайдан килеп чыккан ул?

– Аккош бит инде ул – матур, нәзакәтле кош. Аларны элек патшалар, күзне иркәләп торсыннар, сулыкларны бизәсеннәр дип, махсус рәвештә, күлләргә җибәрткән. Соңгы елларда зоопарк та аларны Кабан күленә җибәрә башлады. Аккошларның үз парларын мәңгелеккә сайлавын да беләбез. Алар гел бергә янәшә йөзә, балаларын да парлап үстерә. Казлар бала чыгарганда, йомырканы ана каз гына басып утыра. Ә аккошларга килгәндә, ата аккош та баса. Шул рәвешле ана аккошны ял иттерә. Әкиятләрдә дә аккош уңай персонаж буларак бирелә. Хәтта бер браконьерның, минем аккошларга атарга кулым күтәрелми, дип әйткәнен беләм. Ә менә аккошлар парларын югалтса, моны күтәрә алмыйча, кыялардан ташланып үлә дию – миф. Парсыз калган аккош икенче бер ялгыз кошны табып парлаша.

– Интернеттагы Кабан күлен чистартучы аккош турындагы видео һәммәбезне дә шаккатырды. Аны чынлап та Экология елының символы дип атый алабызмы?

– Бу аның фәкать оя кору инстинкты. Казлар да бит басып утырганда әйләнә-тирәсендә томшыгына нәрсә эләгә, шуны янына урнаштырып бара. Аккош та шулай итә, күлне чистартса, ул аны бөтенләй читкә чыгарып бара иде.

– Ата сандугач ана кошка мәхәббәтен белдереп сайрый дибез, монысы да мифмы?

– Ата кош иң беренче булып очып килә дә, икенче кошларга, бу минем территориям дигәнне аңлатып, сайрый башлый. Бер куактан икенче куакка күчеп сайрый-сайрый, ул чикләрен билгели. Көчле кошлар иң яхшы урынны алып кала. Чикләр бүленеп беткәч, ана кошлар очып кайта. Аларның да иң көчлеләре лидер ата кошны сайлый.

– Иң акыллы кош – карга, диләр, бу чынлап та шулаймы?

– Каргасыманнар дип тәэтәсем килә. Белгечләрнең әйтүе буенча, алар чынлап та акыллы.

– Кәккүкнең кеше гомерен санавын ничек аңлатасыз?

– Бу уйдырма гына. Каян килеп чыкканын да әйтеп булмый. Кәккүкләрне, йомыркаларын башка кош оясына калдырганнары өчен, яратып та бетермиләр. Әмма без орнитологлар аларны хөрмәт итәбез, чөнки күкеләр табигатьне сакларга булыша. 300 кош арасында алар гына төкле ефәк күбәләге белән туклана. Башка кошлар аларны капса да, төкле булулары аркасында, ашый алмый. Кәккүк булмаса, әлеге күбәләкләр урманны юк итәр иде.

– Күптән түгел генә Кызыл китапның яңа – өченче басмасы чыкты, анда нинди үзгәрешләр бар?

– Һәр ун ел саен берәр китап чыгарып барабыз. Элеккерәк чыкканына, икенче китапка, 70 төрле кош кергән иде. Соңгысында 60ка якын. Китаптан көртлек төшеп калды, чөнки аның саны артты. Тагын берничә кош төшеп калды, аларның Татарстанда булмау факты ачыкланды. Моннан алда чыккан китапта алар искә алынган, чөнки күрүчеләр булган, без исә ул кошларның ялгыш кына очып керүен, безнең территориядә яшәмәүләрен раслый алдык. Бөркетлеләр семьялыгыннан булган орлан – ак койрыкның саны берничә йөзгә җитте, әмма аны әле Кызыл китаптан чыгармыйбыз.

ХӘТЕР

Җиңү өрәңгеләре

Без сугыш елларын кинолардан карап, китаплардан гына укып белмибез, безнең балачак менә шул дәһшәтле заманга туры килде. Корал тотып, ут эчендә үк көрәшмәсәк тә, бу Җиңүдә безнең дә өлешебез зур. Беркөнне почта әрҗәсендә Россия Президенты Владимир Путин кул куйган котлау хатын укыгач, күз алдыма кабат 1945 елның 9 Мае килде. Инде җиде дистәдән артык ел үтсә дә, бу көн хәтеребезгә бик тирән, гомергә онытылмаслык итеп уелган.

1945 елның маенда мин 14 яшьлек үсмер идем. Көрәк күтәрә алырлык бала-чаганы, карт-корыны биш чакрымнан да ерак басуга җир казырга җибәрделәр. Тракторлар юк, атлар сугышта, үгезләр дә калмады. Яз башы бит, чәчәргә кирәк. Ләкин җирне арыш өчен түгел, ә күксагыз үстерү өчен казыйбыз. Ә ул сугыш техникасы тәгәрмәчләрен ясау өчен кирәк ди. Нигә дип сорау бирү юк иде — кирәк һәм бетте китте! «Барысы да җиңү өчен!» дигән девиз гына бар иде. Көчкә сөйрәлеп барып җиттек. Барып җитү белән, җиргә егылдык, ачлы-туклы яшибез бит. Ләкин озак утырыпятып булмый, эшләргә кирәк, без дә көрәкләребезгә тотындык. Бераз казыган идек, авыл ягыннан безгә таба килгән кешене күреп алдык. Дустым Алимҗанның әтисе Шакирҗан бабай икән. Бригадир иде ул. Йөгерә-атлый килгән, яше дә шактый бит, сулышы капкан. Килә-килешкә: «Егетләр, сугыш беткән! Җиңү!» – диде.

Бу изге сүзне ишетү белән, авылга таба дәррәү йөгерә башладык. Барганда көчкә сөйрәлгән аякларга каян көч кергәндер, тигән җиргә тиде, тимәгән җиргә юк.

Хәзер уйлыйм да исем китә, ул чакта бит хәзерге кебек һәр кешедә кесә телефоны юк иде. Радио, телевизор да юк. Кәнсәләрдә (авыл советын шулай диләр иде) авылга бер телефон, ул да бер көн эшли, өч көн юк. Газеталарны да атнага бер тапкыр районнан барып алалар. Шуңа күрә ил яңалыклары безнең Вольный Стан авылына шактый «искереп» кенә килеп ирешә иде.

Ә бу көнне Җиңү хәбәрен ишеткәч тә, Шакир бабай үзе басуга чыгып йөгергән. Карт иде инде ул, шуңа сугышка да алмадылар үзен. Кич белән кайткач, белерләр әле дисә дә, берәү дә гаепләмәс иде югыйсә. Ләкин ул чакта алай уйлаучылар булса, шундый көчле фашистны җиңә дә алмас идек.

Очып авылга кайтсак, анда инде бәйрәм. Капкалар ачып куелган, кешеләр бер-берсен котлыйлар, күбесенең шатланырга да хәле юк, чыкмаган җаннары гына калган.

Кечкенә малайлар:

– Сугыш беткән! Әти кайта! – дип, урам буйлап тузан туздырып чабалар.

Минач бабай, йодрыкларын йомарлап:

– Гитлер мәлгунь, үзең дә беттең, Гыйльметдинемнең генә башына җиттең, – дип такмаклый-такмаклый елый. Аңа башкалар да кушыла…

Сугыш югалтулары бер генә гаиләне дә читләп үтмәде шул. Шушы кечкенә генә авылдан 165 ир-егет яу кырында ятып калган. Хәзер аларның исемнәре клуб янындагы һәйкәлгә алтын хәрефләр белән уелган (рәсемдә). Алар арасында әнинең энесе Идиатулла, апасының малае Рәхимҗан, әтинең энесе Зыятдин һ.б. бик күпләр. Әйе, бу көн, нәкъ җырдагыча, күз яшьле бәйрәм булды. Безнең әти Миндин сугышта түгел, ә хезмәт армиясендә Мәскәү янында иде. Ул әле 1947 елда гына кайтты. Тагын шунысын да әйтим, гел ир балалардан гына торган әтиләр нәселе җиде малайның иң олысы Гыйматдин хәтта Беренче бөтендөнья сугышында, февраль революциясендә патшаны бәреп төшерүдә дә катнашкан. Илнең тарихи вакыйгалары безнең зур нәселдән башка гына булмаган диюем.

Никадәр генә ашыксак та, авылга чапканда, юл буенда баш төрткән үләннәрне җыештыргалаган идем. Авылда өзеп, авызга кабарлык бер үлән дә калмаган – чыккан берсен ашап бетерә тордык. Әнигә шул юлдан җыелган үлән учмаларын бирдем. Ул бакча казыганда чыккан туң черек бәрәңгеләрне дә кушып, алардан кабартмалар пешерде. Әллә Җиңү көне көнне пешерелгәнгә бик тәмле иде алар.

Күңелдә шатлык, тамак та чыгыштырмача тук, бәйрәм истәлеге итеп нидер эшлисе килә. Дустым Алимҗан белән киңәшләштек тә агач утыртырга булдык. Каян алыйк дип, бераз аптырап тордык, чөнки авылыбызда агачлар юк диярлек. Басуда кечкенә генә куаклар күрүебез искә төште. Шунда киттек. Аларны казып, өйгә алып кайтып утырттык. Соңыннан укып белдем, америка өрәңгеләре булган алар. Орлыкларын ерак очыра бит бу агач, кайдандыр килеп төшкән булгандыр инде. Җиңү көнендә утырткан ул өрәңгеләр әле дә исән. Кайтмый калган авылдашларымның: «Тынычлыкның кадерен белегез!» – дигән сүзләре булып пышылдыйлар сыман аның яфраклары.

Тыл һәм хезмәт ветераны
Миңнислам Миндин улы
Вәлиев сөйләгәннәрне
Йолдыз ШӘРАПОВА язып алды.
Буа районы.

«Белсәгез рәхәтлекләрен Әтиле булуларның…»

Әти. Менә шушы өч хәрефтән торган сүзгә күпме мәгънә, наз салынган һәм ниндидер нур, җылылык бөркелә кебек. Сабый баланың: «Әни», – дип, теле ачылса, безнеке: «Әттә», «әти», – дип ачылды.

Әтием син безнең өчен иң газиз, иң кадерле кешебез. Синең бер ягымлы карашың бар борчуны куып таратырга сәләтле, авырганда башыңнан сыйпаса да, үзеңне савыккандай сизәсең, күңел тулганда – тыңлаучы да, юатучы да, киңәш-ярдәм кирәк булганда, чын дус та була беләсең бит син,әти.

Әтием Газинур Минзыя улы Минлебаев Арча районы Иске Ашыт авылында дөньяга килә. Әтиебез әниебез Кадрия белән, авылга мәктәпкә укытырга килгәч танышып, матур гаилә корып җибәргәннәр.

Язмышның кануннары кайчак үзенең кырыс төзәтмәләре белән адәм балаларын сынауларга да дучар итә шул, кызганычка. 33 яшендә сиңа пар канатыңны – әниебезне югалту ачысын татырга туры килә. Бары тик 7 ел да 7 ай гына парлы гомер итәргә насыйп була шул әтиемә. Аяусыз үлем яшьлек өмет-хыялларын чәлпәрәмә китерә… Ике сабый бала ятим кала. Әйе, без бик кечкенә идек шул әниебез үлгәндә, миңа 2 яшь тә 8 ай, ә сеңлемә 7 ай гына була.

Аллага шөкер, әтиебез авырлыклар алдында баш ими, киресенчә, үзендә көч таба, балаларны үстерәсе, аякка бастырасы, кеше итәсе бар дип яши.

Без үскәндә, әтиебезгә бик күп авырлыклар күрергә туры килә, авырып киткән чакларыбыз да, күпме йокысыз үткәрелгән төннәр… Әле ярый әби-бабаебыз, Гөлнур апабыз ярдәменнән ташламадылар, безне тәрбияләргә булыштылар.

Әти күп төрле һөнәр остасы да. Бер минут та тик тора торган кеше түгел. Бүгенге көндә дә йорт-җирне тәзек, чиста, матур итеп тота. Колхозда бик күп еллар шофер булып эшләде. Эштән кайткач, безгә дәрес әзерләргә дә булыша иде. Йорт-каралты тирәсендәге эшләр, лапастагы мал-туар, бакчадагы умарта кортлары… – боларның барысын да ничекләр эшләргә өлгерә идең син, әти ?!

Ир-ат эше, хатын-кыз эше дип аерып тормый – барысына да кулы ята. «Эшнеңояты юк, аны өйрәнеп үсегез. Эшләгәнегез кеше өчен булса, өйрәнгәнегез үзегез өчен», – дип, сеңлем белән икебезне үзе шикелле тырыш булырга өйрәтә, алтынга тиң киңәшләрен бирә.

Әлбәттә, минем бу сүзләремдә бераз мактану да бардыр. Ләкин һәркем өчен үз әтисе газиз, якын һәм кадерле. Ул безнең өчен Әти дә, Әни дә.

Әтием – төп нигезнең җылысын саклаучы да әле. Әбием һәм бабам да әтиебез тәрбиясендә яшәделәр. Алар да безгә үзләренең киңәшләрен бирделәр. Ни кызганыч, әби белән бабам күптән вафат инде.

Әтиебез үзенең әти-әнисенә булган хөрмәте, аларны яратуы аша безнең күңелләргә ата-ана ризалыгы, фатихасы, догасы төшенчәләренең асылын җуелмаслык итеп күңелләргә сеңдерде.

